ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
"ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ"

# ЭШ ПРОГРАММАЛАРЫН ТӨЗҮ БУЕНЧА МЕТОДИК ТӘКЪДИМНӘР

РУС ТЕЛЕНДӘ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
7НЧЕ СЫЙНЫФЫНДА ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАРЫ ӨЧЕН
"ТАТАР ТЕЛЕ" ҺӘМ "ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ" ПРЕДМЕТЛАРЫ БУЕНЧА
ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Казан
2017

ББК 74.268.1Тат+74.268.3Тат
Э98

ТРМҮИ Гыйльми советы карары нигезендә бастырыла

ТРМҮИ ректоры Р.Р. Бәдриеваның гомуми редакциясендә

**Төзүче-авторлар:**

Фәттахова Р.Ф., филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты

Мөхәрләмова Г.Н., филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының татар телен һәм әдәбиятын укытуның хәзерге проблемалары бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре

Сиражетдинова З.П., Казан шәһәре Яңа Савин районы 49 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Дәүләтшина Л.А., Казан шәһәре Яңа Савин районы 49 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Сәфиуллина Г.И., Казан шәһәре 117 нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Ногманова А.И., Казан шәһәре 91 нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Сафина Г.Х., Казан шәһәре 96 нчы гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Закирова А.Х., Казан шәһәре 96 нчы гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр (рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының 7нче сыйныфында татар телен өйрәнүче укучылары өчен "Татар теле" һәм "Татар әдәбияты" предметлары буенча эш программасы) / төз.-авт.: Фәттахова Р.Ф. һәм башк. – Казан: ТРМҮИ, 2017. – 44 б.

"Татар теле" һәм "Татар әдәбияты" предметларының эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр "Россия Федерациясендә Мәгариф турында"гы Федераль законы, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның декабрендә чыккан 1577 номерлы боерыгы, федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә һәм гомуми белем бирүнең төп белем бирү үрнәк программаларын исәпкә алып эшләнде.

Методик тәкъдимнәрдә бирелгән материал белем бирү оешмалары җитәкчеләре, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, методистлар өчен файдалы булачак.

ТРМҮИ, 2017

# КЕРЕШ

Рус телле төркемнәрдә татар телен һәм әдәбиятын укытуның максаты укучыларның коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру, танып белү, гомуми уку күнекмәләрен, сөйләм культурасын үстерү, татар милләтенә, аның тарихи һәм мәдәни хәзинәләренә карата хөрмәт тәрбияләү, укучыларны мәдәниятара диалогка тарту һәм татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүгә ихтыяҗ тудыру белән билгеләнә. Татар теле һәм әдәбияты дәресләре укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә хезмәт итәргә, шулай ук рус телле укучыларны татар халкының мәдәнияты һәм милли үзенчәлекләренә якынайтырга, башка халыкларга карата хөрмәт хисе, толерантлык, мәдәниятара аралашу осталыгы кебек универсаль гамәлләр формалаштыруга этәргеч бирергә тиеш.

Бүгенге көндә укыту процессын системалы-эшчәнлекле юнәлешкә ориентлашып алып бару, укучыларда федераль дәүләт белем бирү стандартларының бер таләбе булган универсаль уку гамәлләрен формалаштыру алгы планга чыга. Һәр уку предметы аерым спецификага ия булып, үзенчәлекләр аның эчтәлегендә, планлаштырылган нәтиҗәләрендә дә чагылыш таба. Болар барысы укытучы төзегән эш программасында исәпкә алына.

Эш программасы – “педагог тарафыннан конкрет белем бирү оешмасы һәм билгеле бер сыйныф (төркем) өчен үрнәк программа нигезендә төзелгән, эчтәлегендә, темаларны өйрәнү эзлеклегендә, сәгатьләр санында, уку-укытуны оештыру формаларын куллануда һ.б. үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне үз эченә алган уку программасы ул”[1], икенче төрле әйткәндә, ул укытучының белем бирү эшчәнлеген оештыру системасын характерлый торган норматив-идарә итү документ.

Ул түбәндәге өлешләрдән тора: аңлатма язуы, уку предметының эчтәлеге, программаның бүлек һәм темаларны үз эченә алган календарь-тематик план, белем бирүнең планлаштырылган нәтиҗәләре, әлеге нәтиҗәләргә ирешүне бәяләү юллары һәм формалары. Гомуми белем бирүнең төрле баскычларында уку-укыту процессы әлеге программадан башка нәтиҗәле итеп оештырыла алмый.

Программаларны эшләү гомуми белем бирү оешмаларының уку-укыту, методик һәм норматив эшчәнлекнең аерылгысыз бер өлеше булып санала. Шул ук вакытта “Россия Федерациясендә Мәгариф турында”гы 273нче номерлы Федераль законы уку предметы, курсы, дисциплинасының (модуленең) эш программасы дигән төшенчәне үз эченә алса да, биредә әлеге төр программага куела торган таләпләр билгеләнми, шул сәбәпле укытучы эш программасын төзегән вакытта төрле характердагы сораулар белән очрашырга мөмкин.

Әлеге методик тәкъдимнәрдә әдәбият предметы буенча эш программасының моделен төзү буенча киңәшләр бирелә, эш программасының структурасы, төп өлешләре, аны төзү юнәлешләре билгеләнә.

Аерым уку предметы буенча төзелгән үрнәк программалар эш программасын төзүдә нигез булып тора, шуңа күрә аның билгеле параметрлары эш программасының структурын, өлешләрен төзүдә хезмәт итә.

Эш программасын төзегәндә аның максатларын, бурычларын һәм фукцияләрен истә тоту зарур.

Эш программасының төп максаты – уку-укытуның билгеле бер баскычында төп белем бирү программасын, планда каралган сәгатьләр санына туры килгән аерым уку предметы буенча үрнәк программаның эчтәлеген, дәрестән тыш эшләр планын, өстәмә белем бирү сәгатьләрен гамәлгә ашыру.

Эш программасының түбәндәгеләр тәшкил итә:

---

[1] Журин А.А. Рабочая программа по учебному предмету: разработка, экспертиза, утверждение: пособие для учителей и руководителей образовательных учреждений общего образования. – М.: Вентана-Граф, 2013. – Б. 14.

- гомуми белем бирү оешмасының белем бирү эшчәнлегенең максатлары, бурычлары һәм укучыларның үзенчәлекләрен исәпкә алып аерым уку предметының эчтәлеген, күләмен, уку материалын өйрәнү тәртибен билгеләү;
- уку еллары һәм белем алу баскычлары эчтәлегенең дәвамчанлыгын тәэмин итү;
- төп гомуми белем бирү оешмасының билгеле бер шартларын, уку ихтыяҗларын һәм укучыларның үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып, педагогик эшчәнлекнең индивидуальлеген чагылдыру.

Эш программасының төп **функцияләре:**

- норматив (эш программасы тулы күләмдә эшләнергә тиеш);
- билгеле бер максатка ирешүне күздә тоту (эш программасы теге яки бу белем бирү өлкәсендә нәтиҗәгә ирешү өчен уку кыйммәтләрен һәм максатларын билгели);
- эчтәлекле (эш программасы укучылар тарафыннан үзләштерергә һәм танып-белергә тиеш булган уку элементларының эчтәлеген, шулай ук аларның авырлык дәрәҗәсен билгеләүне күздә тота);
- процессуаль (эш программасы эчтәлек элементларын үзләштерүнең логик эзлеклелеген, уку-укытуны оештыру формаларын, методларын, чараларын һәм шартларын, шулай ук уку-укыту процессының әлеге предмет буенча дәвамчанлыгын билгели);
- бәя бирүче (эш программасы эчтәлек элементларын үзләштерүнең дәрәҗәсен, контрольгә алынучы объектны, контроль төрләрен һәм укучыларны бәяләү критерийларын ачыклый).

Аерым уку предметы буенча эш программасы РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның декабрендә чыккан 1577 номерлы боерыгы буенча эш түбәндәге өлешләрдән торырга тиеш:

1) аерым уку предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре;
2) дәресләрне оештыру формаларын, укучыларның төп эшчәнлек төрләрен күрсәткән аерым уку предметының эчтәлеге;
3) һәр теманы үзләштерүгә бүлеп бирелгән сәгатьләрне күрсәткән календарь-тематик план.

Аерым уку предметы буенча эш программасын килештерү һәм раслауның тәртибе гомуми белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә.

**Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләренең
рус төркемендәге 7 нче сыйныф укучылары өчен татар теленнән
эш программасы**

Т ө з ү ч е - а в т о р л а р:

Сираҗетдинова Зоя Петр кызы, Казан шәһәре Яңа Савин районы 49 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Дәүләтшина Лилиана Азат кызы, Казан шәһәре Яңа Савин районы 49 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Эш программасы түбәндәге хокукый-норматив документларны исәпкә алып төзелде:

1. Россия Федерациясенең “Мәгариф турында” Законы (№273, 29.12.2012 ел).
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында” Законы (ТРЗ-68 22.07.2013 ел).
3. Төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты (РФ Мәгариф министрлыгының 1897нче боерыгы белән кертелгән, 17нче декабрь, 2010 нчы ел).
4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1-11 нче сыйныфлар). Төзүче-авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л. Малафеева. – Казан, 2014.
5. Муниципаль белем бирү оешмасының төп гомуми белем бирү планы.

**Укыту предметының укыту планында тоткан урыны**

Мәктәпнең укыту планында каралганча, татар теле дәресләре өчен атнага – 2 сәгать исәбеннән елга 70 сәгать бирелә.

Дәреслек: Р.З. Хәйдәрова, Г.М.Әхмәтҗанова, Р.Л.Малафеева. Татар теле. 7нче сыйныф. - Рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). - Казан, “Татармультфильм”, 2014.

## ПРОГРАММАНЫ ҮЗЛӘШТЕРҮНЕҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘРЕ

### Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

- Туган җиргә мәхәббәт, үз илең өчен горурлык хисләре формалашу;
- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булу һәм аны яхшы өйрәнү теләге туу;
- укучының тоткан урынын, укучы ролен кабул итү, укуга карата кызыксыну уяну, укуның шәхсән мәгънәсен аңлау;
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау, төп мораль нормаларны белү;
- өлкәннәр, сыйныфташлар, дуслар белән уңай мөгалләмәдә булу, ихтирамлылык, кайгыртучанлык, мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлар формалашу.

### Метапредмет нәтиҗәләре

***Танып белү универсаль уку гамәлләре (ТБУУГ):***

- эзләнү, танышу, өйрәнү, үзләштерү, анализлау характерындагы уку нигезләре формалашу;
- төшенчәләргә билгеләмә бирү, гомумиләштерү, модельләштерү, нәтиҗә ясау;
- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр формалашу: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерләү;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү, уртак һәм аермалы билгеләрне таба белү;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
- тиешле мәгълүматны табу өчен төрле ресурсларны куллану;
- фәнни-тикшеренү, проект эшләрен үтәү нигезләрен белү.

***Коммуникатив универсаль уку гамәлләре (КУУГ):***

- татар теленең грамматик һәм стилистик нормаларына нигезләнеп, монгологик һәм диалогик сөйләм төзү күнекмәләренә ия булу;
- аралашу бурычлары һәм шартларына туры китереп фикерне белдерә алу;
- башкаларны тыңлый һәм ишетә белү;
- укылган текстлар буенча сораулар бирә алу;
- бирелгән текстларның дәвамын сөйли алу;
- сыйныфташлар каршында төрле темаларга, башкарылган проектлар буенча чыгыш ясау;
- сораулар ярдәмендә мәгълүматны таба алу;
- әңгәмәдәшнең үз-үзен тотышы белән идарә итү – аның гамәлләрен күзәтү, төзәтү һәм бәяләү, ышандыра алу;
- төркемдә конфликтсыз эшләүне тәэмин итү, үзара ярдәмләшү;
- әңгәмәдәшләргә хөрмәтле караш булу.

***Регулятив универсаль уку гамәлләре (РУУГ):***

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләре булу.

**Предмет нәтиҗәләре**

- сөйләм эшчәнлеге төрләре камилләшү;
- аерым темалар буенча аралашуда татар теленең лингвистик, стилистик мөмкинлекләреннән оста файдалану;
- татар теленең әйтелеш нормаларын саклап, сәнгатьле һәм аңлап уку;
- өйрәнелгән темалар буенча актив кулланылышта булган сүзләрне дөрес язу;
- исем, сыйфат, рәвеш, затланышлы һәм затланышсыз фигыльләрнең лексик-грамматик үзенчәлекләрен үзләштерү, сөйләмдә дөрес куллану;
- теркәгеч, кисәкчә, мөнәсәбәт белдерүче сүзләрнең җөмләдәге ролен аңлау, аларны сөйләмдә дөрес куллану;
- җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен аеру, аларның синтаксик функцияләрен белү.

Укучы, 7нче сыйныфны тәмамлаганда, сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча түбәндәге белем-күнекмәләргә ия булырга тиеш.

**Диалогик сөйләм**. Программа кысаларындагы тематикада диалогик сөйләм күнекмәләре камилләшү: диалог – сораштыру, диалог – тәкъдим, диалог – фикер алышу, катнаш диалоглар. Диалог күләме: һәр катнашучы ягыннан кимендә 8-9 реплика әйтә белергә тиеш.

**Монологик сөйләм.** Программада тәкъдим ителгән темалар кысасында сөйләмнең коммуникатив типлары буенча бәйләнешле сөйләм камилләшү: сурәтләп сөйләү, эчтәлек сөйләү, хикәя төзү, хәбәр итү. Монологик сөйләм күләме: кимендә 8-10 фраза.

**Тыңлап аңлау.** Программада тәкъдим ителгән эчтәлек нигезендә төрле төрдәге тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү; сүзләрне, җөмләләрне аңлап тәрҗемә итә белү; мәгълүмати характердагы текстларны, вакытлы матбугат язмаларын тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикер әйтү, аралашуга чыгу.

**Уку.** Программаның предмет эчтәлегенә туры килгән әдәби, фәнни-популяр, рәсми характердагы текстлар белән танышу барышында, мәгълүмат белән эшләү күнекмәләренә ия булу.Мәгълүматны танып белү, үзләштерү ихтыяҗыннан чыгып, тәкъдим ителгән текстларны аңлап укырга өйрәнү.Текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлау.

**Язу.** Программада тәкъдим ителгән эчтәлек нигезендә актив куллануда булган сүзләрне дөрес яза, төрле калыптагы диалоглар, конкрет бер тема буенча хикәя төзи белү, дөрес яза белү. Язма эшнең күләме: 55 – 65 сүзгә кадәр.

## Төп эчтәлекнең бүленеше (70 сәг.)

| № | Сәгать-ләр саны | Темалар | Тематик эчтәлек | |
|---|---|---|---|---|
| | | | **Коммуникатив юнәлеш** | **Грамматика** |
| **I.** | 23 | Белем һәм тормыш | Яңа уку елындагы яңалыклар, җәйге ялны ничек уздыру, классташларыңның ничек укуы, нинди билгеләр алу, өй эшен ничек эшләү, дәрестә ничек катнашу турында сөйләшү. Начар билгегә үз карашыңны белдерү. Уку-язу әсбапларын тәртиптә тоту, яхшы уку серләре, яхшы уку өчен нинди холык сыйфатларның кирәклеге турында сөйләшү. | Ясалышы буенча сыйфат төрләре.<br>Билгеле һәм билгесез үткән заман хикәя фигыльләр.<br>Боерык фигыльнең зат-сан белән төрләнеше.<br>Хәл фигыльнең 4 төре.<br>Рәвеш төркемчәләре.<br>Сәбәпне белдерү формалары.<br>Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибе. |
| **II.** | 20 | Без бергә ял итәбез | Буш вакыт. Буш вакытны файдалы, файдасыз үткәрү. Яшьтәшләрнең үз-үзләрен җәмгыять урыннарында тотышы турында сөйләшү, бәя бирү.<br>Яраткан шөгыль турында әңгәмә кору. Спорт түгәрәкләренә йөрү, спорт уеннарында катнашу, спорт чараларын, тапшыруларын карау турында сөйләшү. | Сыйфат фигыльнең заман формалары.<br>Җөмләнең баш кисәкләре: ия һәм хәбәр, алар арасында сызык куелу очраклары.<br>Теркәгечләр. Җыючы (һәм, да-дә, та-тә, ни...ни), каршы куючы (ләкин, ә, әмма, тик), бүлүче (я, яки, яисә, әле, әллә) теркәгечләр.<br>Ияртүче (чөнки, әгәр, гүя, ягъни, гәрчә, ки) теркәгечләр.<br>Исем фигыльнең барлык, юклык формасы. Мөнәсәбәт белдерүче сүзләр.<br>Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. |
| **III.** | 16 | Өлкәннәр һәм кечкенәләр | Өлкәннәр һәм кечкенәләрнең гаиләдә үзара мөнәсәбәте, кушкан эшкә җаваплы караш турында сөйләшү. Өлкәннәргә үзеңнең кая барырга, нишләргә теләгәнеңне, кайчан кайтасыңны әйтү, өлкәннәрдән рөхсәт сорарга өйрәнү. Гаиләдә бергә бәйрәмнәр үткәрү турында әңгәмә кору, әти-әниләрне бәйрәм белән котлау. | Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре.<br>Җөмләнең иярчен кисәкләре: аергыч, тәмамлык, хәл.<br>Исем фигыльнең килеш белән төрләнеше.<br>Кисәкчәләр һәм аларның төркемчәләре. Кисәкчәләрнең дөрес язылышы. |
| **IV.** | 11 | Без Татарстанда яшибез | Татарстанның табигате, аның табигый байлыклары турында сөйләшү. Туган як табигатенә карата фикер белдерү. Татарстанның территориясе, аның географик урыны, зур елгалары, шәһәрләре турында сөйләшү. | Теләк фигыль. Теләк фигыльнең 1нче зат берлек һәм күплек сан формалары.<br>Максатны белдерү формалары. |

# КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Дәрес темасы | Дәрес эчтәлеге | Планлаштырылган нәтиҗәләр | | | Контроль төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Шәхескә кагылышлы | Метапредмет | Предмет | | План | Факт |
| | **I. Белем һәм тормыш. 23 сәг.** | | | | | | | |
| 1 | “Яңа уку елы" темасы буенча лексик-грамматик материал. | Яңа уку елы турында әңгәмә оештыру. Белем бәйрәме турында сөйләшү. Исемнәрне кабатлау. | Татар теленә карата ихтирамлы караш барлыкка килү һәм аны яхшы өйрәнү теләге туу, дәрестә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белү; мәктәп таләпләрен үтәргә әзер булу. | **ТБУУГ:** дәреслектән кирәкле мәгълүматны табу һәм аңлау. **КУУГ:** әңгәмәдә катнашу, сорауларга җавап бирә, үз фикереңне әйтә белү, башкаларны тыңлау. **РУУГ:** дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү, дәрестә эш тәртибен аңлау, тема буенча уку эшчәнелеген оештыра алу. | Яңа уку елы турында әңгәмәдә катнашу, исем сүз төркеме турында белемнәрнең актуальләшүе. | | | |
| 2 | Сыйфатлар ясалышы. | Сыйфатларның ясалышы турында төшенчә алу. Сыйфатларның кушымчалау ысулы белән ясалышын өйрәнү. | Башкаларга карата хөрмәт, кайгыртучанлык хисләре формалашу. Матурлыкны күрә, тоя белү. | **ТБУУГ:** уку мәсьәләсен чишкәндә логик фикерли алу, төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыра белү. **КУУГ:** башкаларның сөйләмен тыңлый, сораулар бирә белү, башкаларга аңлаешлы сөйләм төзи алу. **РУУГ:** танып белү мәсьәләсен мөстәкыйль ачыклый һәм максат куя белү. | Кушымчалар ярдәмендә сыйфатлар ясый белү, аларны тексттан таба алу, сөйләмдә куллана алу. | | | |
| 3 | Җәйге ял. Билгеле үткән заман хикәя фигыль. | Билгеле үткән заман хикәя фигыльләрне дөрес куллану күнекмәсе булдыру, биремнәр үтәү. ”Минем җәйге ялым” темасына әңгәмә оештыру. | Ял вакытында сәламәтлекне саклауның кирәклеген аңлау, башкаларга карата кайгыртучанлык хисләре формалашу. | **ТБУУГ:** текстны аңлап уку; өзектән кирәкле мәгълүматны сайлап ала белү, үзләштерелгән белемнәрне куллана белү. **КУУГ:** башкаларның позициясен кабул итү, аңлау, үзара хөрмәт нигезендә диалог алып бара белү, диалогта катнашу. **РУУГ:** уку проблемасын чишү өчен план төзү, максатка ирешү юлларын билгеләү. | Билгеле үткән заман хикәя фигыльләрне кулланып, рәсемнәр буенча җөмләләр төзи белү. Җәйге каникулда кайда булу, ничек ял итү турында кирәкле лексик берәмлекләрне кулланып сөйли алу. | | | |
| 4 | Билгесез үткән заман хикәя фигыль. | Билгесез үткән заман хикәя фигыльләрне өйрәнүне дәвам | Үзара мөнәсәбәтләрдә әдәплелек нормаларын | **ТБУУГ**: кабатлау, өйрәнү, үзләштерү һәм эзләнү характерындагы уку нигезләре формалашу. **КУУГ**: бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат | Фигыльнең үткән заман формаларын белү, аларны язма һәм телдән сөйләмдә дөрес | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | итү, фигыльләр турында алган белемнәрне кабатлау, биремнәр үтәү. | үтәүнең кирәклеген аңлау. | алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү.<br>**РУУГ**: уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели, аларны чишә белү. | куллану. | | | |
| 5 | Фигыльнең үткән заман формалары. | "Фигыльнең үткән заман формалары" темасына контроль эш эшләү. | Башкаларга карата түземлелек хисләре формалашу, мәктәп тормышы таләпләрен, укучы бурычларын үтәргә әзер булу. | **ТБУУГ**: эшне башкарганда, биремнәрне аңлап, мөстәкыйль рәвештә язма формада үтәү.<br>**КУУГ:** аралашу максатына һәм шартларына туры китереп, үз фикереңне җитәрлек дәрәҗәдә тулы һәм төгәл итеп әйтә белү.<br>**РУУГ:** регулятив коррекция. | Кушымчалар ярдәмендә фигыльнең үткән заман формаларын ясый, аларны текстта таба белү, язма сөйләмдә куллана алу. | Контроль эш | | |
| 6 | Хаталар өстендә эш Хәл фигыль. | Контроль эштә җибәрелгән хаталарны төзәтү буенча эш. Хәл фигыльнең грамматик билгеләре белән таныштыру, биремнәр үтәү. | Ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләр формалашу. | **ТБУУГ**: кабатлау, өйрәнү, үзләштерү, хаталарны төзәтү характерындагы уку нигезләре формалашу.<br>**КУУГ**: үз фикереңне аргументлар белән нигезләү, үз эшчәнлегеңне, танып-белүне дөрес оештыру өчен кирәкле сораулар бирү.<br>**РУУГ**: үзрегуляция. | Хәл фигыль турында төшенчә алу, язма һәм телдән сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәнү. | | | |
| 7 | Хәл фигыльнең 4 төре. | Хәл фигыльнең дүрт формасын өйрәтнү, аларны аеру, мәгънәләренә төшенү һәм сөйләмдә куллану буенча күнегүләр үтәү. | Әхлакый нормаларны кузаллауга нигезләнеп, эшләгән эшләр өчен шәхси җаваплылык, мөстәкыйльлек формалашу. | **ТБУУГ:** төшенчәләргә билгеләмә бирү, гомумиләштерү; танышу, өйрәнү, үзләштерү һәм эзләнү характерындагы уку нигезләре.<br>**КУУГ:** бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү.<br>**РУУГ:** эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү. | Хәл фигыль формаларын аера һәм куллана белү | | | |
| 8 | "Мәктәптә беренче көн" темасы буенча әңгәмә. Хәл фигыль формаларын кабатлау. Сүзлек эше. | Хәл фигыль формаларын актив кулланылышка кертү, текст буенча эшләү, биремнәр үтәү. | Укуга кызыксыну, уңай караш булу. Дусларга, сыйныфташларга карата дуслык, кайгыртучанлык хисләре формалашу. | **ТБУУГ:** текст белән эшләү, эзләнү, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗәләр чыгару кебек уку нигезләре формалашу.<br>**КУУГ:** бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү.<br>**РУУГ:** дәрес бурычларын аңлап, теманы үзләштерү буенча эшчәнлекне нәтиҗәле | Хәл фигыль формаларын тексттан аерып күрсәтә белү, төп грамматик билгеләрен белү, сөйләмдә грамоталы һәм актив куллана алу. | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | итеп оештыра алу. | | | | |
| 9 | Хәл фигыль формаларын сөйләмдә куллану. | Хәл фигыль формаларын ныгыту буенча эшчәнлек. | Укучының тоткан урынын, укучы ролен кабул итү, укуга карата кызыксыну уяну, укуның шәхсән мәгънәсен аңлау. | **ТБУУГ:** белемне структуралаштыру, гомумиләштерү, логик фикерләү кебек уку нигезләре формалашу.<br>**КУУГ:** диалогик һәм монологик сөйләм төзегәндә нәтиҗәле ысулларны сайлап алу, татарча граматолы итеп сөйләшергә һәм язарга омтылу.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне планлаштыра, максат куя белү, куелган максатларга ирешүгә юнәлтелгән эшчәнлек белән идарә итү. | Хәл фигыль турында белемнәрнең активлашуы, формаларын бәйләнешле сөйләмдә куллана белү. | | | |
| 10 | Боерык фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | ”Без бергә дәрес әзерлибез” темасы буенча әңгәмә кору, боерык фигыльнең зат-сан белән төрләнеше буенча белемнәрне ныгыту. | Башкалар хисен аңлау, кайгырта белү, ярдәмчелек сыйфатларының әһәмиятен аңлау. | **ТБУУГ**: тиешле мәгълүматны табу өчен төрле ресурсларны куллана алу.<br>**КУУГ**: төрле коммуникатив максатларга ирешү өчен телдәге чараларны дөрес куллану, телдән һәм язма сөйләм күнекмәләренә ия булу, контексттан чыгып диалог төзү.<br>**РУУГ**: укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү. Үзрегуляция. | Боерык фигыльне зат-сан белән төрләндерә һәм аларны сөйләмдә куллана белү, ”Без бергә дәрес әзерлибез” темасына диалог төзи алу. | | | |
| 11 | Зәкия Туфайлованың “Самат" шигыренә караган лексик-грамматик материал. | Зәкия Туфайлованың “Самат" шигыренә караган лексик-грамматик материалны үзләштерү. | Китапка, уку-язу әсбапларына сакчыл караш булу. Китап кадерен белү кебек сыйфатлар формалашу. | **ТБУУГ**: укуның төрле формаларыннан файдалану (аңлап уку, өстән-өстән, эчтәлекне аңлап), укылган мәгълүматка бәйле гади нәтиҗәләр ясау.<br>**КУУГ**: бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү.<br>**РУУГ**: кабул ителгән карарларның дөреслеген мөстәкыйль рәвештә бәяли, төрле үзгәрешләр кертә белү. | Зәкия Туфайлованың “Самат" шигыренә караган яңа лексик берәмлекләрне актив лексикага кертү һәм эчтәлеген белү. | | | |
| 12 | Боерык фигыльләрне кабатлау. Сүзлек эше. | Боерык фигыльләрне кабатлау. ”Без китапханәгә йөрибез” темасына бәйләнешле текст төзү, тема буенча сүзлек эше. | Әдәплелек сыйфатлары, китапларга сакчыл караш формалашу. | **ТБУУГ**: текст белән эшләү, кирәкле мәгълүматны табу, кабатлау, эзләнү, чагыштыру, анализлау, гомумиләштерү, нәтиҗәләр чыгару характерындагы уку нигезләре формалашу.<br>**КУУГ**: бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү, фикерне төгәл, тулы белдерү, башкаларның позициясен | ”Без китапханәгә йөрибез” темасына бәйләнешле текст төзи белү, алган белемнәрне кулланып, тема буенча сүзлек эше башкару. Саматның гамәлләренә бәя бирә белү. | Сүзлек эше. | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | истә тотып эш итә белү, текст төзегәндә нәтиҗәле ысулларны сайлап алу, татарча граматолы итеп сөйләшергә һәм язарга омтылу.<br>**РУУГ**: эшчәнлекне планлаштыра белү, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | | | | |
| 13 | Рәвеш төркемчәләре. | Сүз төркемнәрен искә төшерү. Рәвешләрнең ясалышы һәм мәгънәсе, кулланылышы, рәвеш төркемчәләре, рус теле белән уртак һәм аермалы яклары. | Үзара мөнәсәбәтләрдә мораль нормаларны үтәргә кирәклеген аңлау. | **ТБУУГ:** төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү. Объектларны чагыштыру, классификацияләү, уртак билгеләрне таба белү.<br>**КУУГ:** укытучы һәм сыйныфташлар белән белем алу эшчәнлеген оештыру, продуктив хезмәттәшлек итү, аралашу күнекмәләре формалашу.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне планлаштыра, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | Рәвешләрне кулланып җөмлә төзи алу, диалогик, монологик сөйләмдә дөрес куллану. | | | |
| 14 | Рәвеш төркемчәләре. | Рәвеш төркемчәләрен өйрәнүне дәвам итү. Урын һәм вакыт рәвешләре турында аңлату, аларны куллану өстендә эш. ”Без китаплар укыйбыз” темасына әңгәмә. | Китап укуның файдалы булуын тану. | **ТБУУГ:** кабатлау, эзләнү, чагыштыру, анализлау, гомумиләштерү, нәтиҗәләр чыгару характерындагы уку нигезләре формалашу.<br>**КУУГ:** бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү, үз фикереңне төгәл, тулы белдерү, башкаларның позициясен истә тотып эш итә белү, диалогик һәм монологик сөйләм төзегәндә нәтиҗәле ысулларны сайлап алу, татарча граматолы итеп сөйләшергә һәм язарга омтылу.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне планлаштыра белү, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | Урын һәм вакыт рәвешләрен куллана белү. ”Без китаплар укыйбыз” темасына әңгәмә оештыра белү. | | | |
| 15 | Контроль эш. Фигыль төркемчәләре | Фигыль төркемчәләре темасына контроль эш башкару. | Башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык хисләре формалашу, | **ТБУУГ:** тема буенча белемнәрне структуралаштыру, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү; эшне башкарганда биремнәрне аңлап мөстәкыйль рәвештә язма формада үтәү. | Алган белемнәрне гамәлдә куллана белү. | Контроль эш | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | мәктәп тормышы таләпләрен, укучы бурычларын үтәргә әзер булу. | **КУУГ:** үз фикереңне төгәл, тулы белдерү, дәлилли алу, карар кабул итү, сайлау алдыннан төрле фикерләрне чагыштыру һәм ачыклау.<br>**РУУГ:** үзрегуляция. | | | | |
| 16 | Хаталар өстендә эш. Фигыль төркемчәләрен кабатлау. | Хаталар өстендә эш башкару, фигыль төркемчәләрен кабатлау, биремнәр үтәү. | Башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык хисләре формалашу, мәктәп тормышы таләпләрен, укучы бурычларын үтәргә әзер булу. | **ТБУУГ:** кабатлау, өйрәнү, үзләштерү, хаталарны төзәтү һәм нәтиҗә ясау характерындагы уку нигезләре формалашу.<br>**КУУГ:** үз фикереңне төгәл, тулы белдерү, аралашуда тел чараларыннан урынлы һәм грамоталы файдалану, төркемнәрдә эшли алу, башкаларның фикерләрен тыңлап, уртак фикергә килү.<br>**РУУГ:** Билгеләнгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү.<br>Кичәге һәм бүгенге уңышларны чагыштыру. | Фигыль төркемчәләрен дөрес куллана белү, хаталарны аңлап, кирәкле төзәтмәләр кертү, "Без киңәшләр бирәбез" дигән темага әңгәмәдә катнаша алу. | | | |
| 17 | Сәбәпне белдерү формалары. | Рәвеш төркемчәләрен искә төшерү. Сәбәп-максат рәвешләре турында төшенчә булдыру, күнегүләр башкару. | Укуда, хезмәттә ихтыяр көченең зарурлыгын аңлау. | **ТБУУГ**: Логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, тәкъдим ителгән билгеләр буенча төшенчәне әйтү, өйрәнелгән объектларга кыскача характеристика бирә алу.<br>**КУУГ:** укытучы һәм сыйныфташлар белән белем алу эшчәнлеген оештыру, продуктив хезмәттәшлек итү, аралашу күнекмәләре формалашу.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне планлаштыра, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | Сәбәп-максат рәвешләрен башка рәвешләрдән аера белү һәм куллана алу, диалогик, монологик сөйләмдә дөрес куллану. | | | |
| 18 | Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибе. | Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибен искә төшерү, биремнәр эшләү. | Яшьтәшләргә, сыйныфташларга карата игътибарлы, сабыр булу. | **ТБУУГ:** эзләнү, анализ, синтез, чагыштыру, уртак билгеләрне таба белү, үрнәк буенча эшли алу нигезләре булу, тәрҗемә итү.<br>**КУУГ:** нәтиҗәле хезмәттәшлек итү, үзара ярдәм һәм контрольне тормышка ашыру.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне планлаштыра белү, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибен үзләштерү, татар һәм рус телләрендә кушымчалар ялгану тәртибен чагыштырып нәтиҗә ясый алу, язмача һәм телдән сөйләмдә исемнәрне дөрес грамматик | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | формада куллану. | | | |
| 19 | "Көндәлек-документ, көндәлек -синең көзгең" темасы буенча лексик-грамматик материал. | "Көндәлек-документ, көндәлек - синең көзгең" темасы буенча лексик-грамматик материал белән таныштыру, күнегүләр эшләү. | Уку-язу әсбапларына карата сакчыл караш кирәклеген аңлау, көндәлек алып баруның мөһимлеген тану. | **ТБУУГ:** уку мәсьәләсен чишкәндә логик фикерли алу, төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру, төшенчә чыгару, модельләштерү, төп мәгълүматны билгеләү, үрнәк буенча биремнәр эшли алу, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү.<br>**КУУГ:** укытучы һәм сыйныфташлар белән белем алу эшчәнлеген оештыру, продуктив хезмәттәшлек итү, аралашу күнекмәләре формалашу.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне планлаштыра, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | Текстка караган яңа лексик берәмлекләр белән танышу, эчтәлеген белү һәм аларны сөйләмдә куллана алу. | | | |
| 20 | Безнең көндәлекләребез. | Рәвеш төркемчәләре буенча белемнәрне ныгыту, грамматик күнегүләр эшләү. | Уку-язу әсбапларына карата сакчыл караш кирәклеген аңлау, көндәлек алып баруның әһәмиятен белү. | **ТБУУГ:** эзләнү, анализ, синтез, чагыштыру, үрнәк буенча эшли алу нигезләре; текстны укып, эчтәлегенә бәя бирү, проблеманы аерып чыгарып формалаштыру, аны чишү өчен план төзү, максатка ирешү юлларын билгеләү.<br>**КУУГ:** нәтиҗәле хезмәттәшлек итү, үзара ярдәм һәм контрольне тормышка ашыру.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне планлаштыра белү, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | Рәвешләрне тексттан таба белү, ”Безнең көндәлекләребез” темасына монологик сөйләм төзи белү. | | | |
| 21 | "Яхшы уку кагыйдәләре" темасы буенча лексик-грамматик материал. | “Яхшы уку кагыйдәләре” темасы буенча лексик-грамматик материалны үзләштерү буенча эшчәнлек. | Яхшы уку кагыйдәләрен белү. | **ТБУУГ:** төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү, эзләнү, анализ, синтез, чагыштыру, үрнәк буенча эшли алу нигезләре.<br>**КУУГ:** нәтиҗәле хезмәттәшлек итү, үзара ярдәм һәм контрольне тормышка ашыру.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне планлаштыра белү, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | “Яхшы уку кагыйдәләре” темасы буенча әңгәмә кора белү,<br>тема буенча лексик-грамматик материалны үзләштерү. | | | |
| 22 | “Инфинитив +кирәк” төзелмәсе. | Инфинитив + кирәк төзелмәсен искә төшерү. | Уку һәм һөнәри эшчәнлек арасында бәйләнешнең мөһим булуын | **ТБУУГ:** кабатлау, эзләнү, чагыштыру, анализлау, гомумиләштерү, нәтиҗәләр чыгару характерындагы уку нигезләре формалашу. | Инфинитив +кирәк төзелмәсен кулланып, җөмләләр төзи алу. | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | аңлау. | **КУУГ:** бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү, үз фикереңне төгәл, тулы белдерү, башкаларның позициясен истә тотып эш итә белү, диалогик һәм монологик сөйләм төзегәндә нәтиҗәле ысулларны сайлап алу, татарча граматолы итеп сөйләшергә һәм язарга омтылу.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне планлаштыра белү, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | | | | |
| 23 | Үтелгән темалар буенча сүзлек эше. | Үтелгән темалар буенча сүзлек эше эшләү. | Яхшы укуга, тирән белем алуга омтылыш булу. | **ТБУУГ**: тема буенча белемнәрне структуралаштыру, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү; эшне башкарганда биремнәрне аңлап мөстәкыйль рәвештә язма формада үтәү.<br>**КУУГ**: бердәм эшчәнлектә укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү, фикерне төгәл, тулы белдерү, башкаларның позициясен истә тотып эш итә белү, җөмлә төзегәндә нәтиҗәле ысулларны сайлап алу, татарча граматолы итеп сөйләшергә һәм язарга омтылу.<br>**РУУГ**: укытучы белән бергәләп, үз эшен планлаштыра белү, максат куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен контрольгә ала белү. | Алган белемнәрне практикада куллана белү. | Сүзлек эше | | |
| **II. Без бергә ял итәбез. 20 сәг.** | | | | | | | | |
| 24 | Сыйфат фигыльнең заман формалары. | Сыйфат фигыльнең заман формалары белән танышу, таблица белән эш. | Файдалы ял итү төшенчәсе барлыкка килү. | **ТБУУГ:** танышу, төшенчәләргә билгеләмә бирү, өйрәнү, үзләштерү һәм укытучы ярдәме белән алгоритм төзи, шуның буенча эшли белү.<br>**КУУГ:** мәгълүматны туплау өчен, кумәк эштә катнашу.<br>**РУУГ:** уку мәсьәләсен кабул итү һәм укытучы күрсәтмәсенә иярү, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү. | Сыйфат фигыльнең заман формаларын бәйләнешле сөйләмдә дөрес итеп куллану, алар кергән җөмләләрне ишетеп аңлау. | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 25 | Сыйфат фигыльләрнең сөйләмдә кулланылышыТест. | Сыйфат фигыльнең юклык формасы белән таныштыру, аның сөйләмдәге роле, рус теле белән уртак һәм аермалы якларын табу. Тест эшләү. | Башкаларга карата хөрмәт, кайгыртучанлык хисләре формалашу. Матурлыкны күрә, тоя белү. | **ТБУУГ:** иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру; тиешле мәгълүматны табу өчен сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.<br>**КУУГ:** коммуникатив уен һәм уку ситуациясенә керү, диалогик һәм монологик сөйләм төзегәндә нәтиҗәле ысулларны сайлап алу, татарча граматолы итеп сөйләшергә һәм язарга омтылу.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне планлаштыра белү, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | Сыйфат фигыльләрне диалогик, монологик сөйләмдә куллана белү, рус теле белән уртак һәм аермалы якларын таба алу. | Тест | | | |
| 26 | Җөмләнең баш кисәкләре. | Җөмләнең баш кисәкләре: ия, хәбәрне аерырга өйрәнү, биремнәр эшләү. | Шәһәрнең истәлекле урыннарына, театр сәнгатенә карата кызыксыну уяну. | **ТБУУГ**: Логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, тәкъдим ителгән билгеләр буенча төшенчәне әйтү, өйрәнелгән объектларга кыскача характеристика бирә алу.<br>**КУУГ:** хезмәттәшлектә үз фикереңне формалаштыра, аргументлаштыра һәм уртак эшчәнлектә башкалар позициясе белән килештерә алу.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне планлаштыра, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | Җөмләнең баш кисәкләре ия белән хәбәрне таба белү, рус һәм татар телендәге җөмләнең баш кисәкләрен мисаллар ярдәмендә чагыштыра белү; шәһәребезнең истәлекле урыннары турында сөйли белү. | | | | |
| 27 | ”Буш вакыт”темасына караган лексик-грамматик материал. | ”Буш вакыт”темасына караган лексик-грамматик материал белән танышу, рус теленә тәрҗемә итү. | Вакытның кадерен белү, аны файдалы үткәрергә кирәклегенә инану. | **ТБУУГ**: укуның төрле формаларыннан файдалану (аңлап уку, өстән-өстән, эчтәлекне аңлап), укылган мәгълүматка бәйле гади нәтиҗәләр ясый алу.<br>**КУУГ**: сөйләшү предметына яки объектына карата төрле карашлар булу мөмкинлеген аңлау.<br>**РУУГ:** уку проблемасын чишү өчен план төзү, максатка ирешүдә нәтиҗәле ысуллар сайлау. | ”Буш вакыт” темасы буенча әңгәмә кора һәм фикер алыша белү, бу темага караган лексик-грамматик материалны дөрес куллану. | | | | |
| 28 | Ия белән хәбәр арасындагы сызык. Үткәннәрне кабатлау. | Ия белән хәбәр арасындагы сызык куелу очраклары белән таныштыру, грамматик | Укуда, хезмәттә кичәге һәм бүгенге уңышларыңны чагыштыру,баш-каларны тыңлау, | **ТБУУГ**: текст белән эшләү, кирәкле мәгълүматны табу, кабатлау, чагыштыру, текстның төп берәмлекләрен символ (тамга) белән билгеләү.<br>**КУУГ**: бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат | Ия белән хәбәр арасындагы сызык куелу очракларын аңлау, аерым фикерләрне исбатлау | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | күнегүләр эшләү. | уңышларың белән уртаклаша белү. | алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү; парлап һәм төркемдә эшли белү.<br>**РУУГ**: эшчәнлекне планлаштыра белү, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | һәм кире кагу, тема буенча әңгәмәдә катнашу. | | | |
| 29 | Контроль эш. Җөмлә кисәкләре. | “Җөмлә кисәкләре” темасына контроль эш башкару. | Башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык хисләре формалашу, мәктәп тормышы таләпләрен, укучы бурычларын үтәргә әзер булу. | **ТБУУГ:** тема буенча белемнәрне структуралаштыру, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү; эшне башкарганда биремнәрне аңлап мөстәкыйль рәвештә язма формада үтәү.<br>**КУУГ:** үз фикереңне төгәл, тулы белдерү, карар кабул итү, сайлау алдыннан төрле фикерләрне чагыштыру һәм ачыклау; биремнәрне үтәгәндә нәтиҗәле ысулларны сайлап алу, татарча граматолы итеп язарга омтылу.<br>**РУУГ:** үзрегуляция. | Алган белемнәрне практикада куллана белү. | Контроль эш. | | |
| 30 | Хаталар өстендә эш. Грамматик күнегүләр эшләү. | Хаталар өстендә эш башкару, грамматик күнегүләр эшләү. | Китап укуның файдасын аңлау; активлыкка, мөстәкыйльлеккә омтылу. | **ТБУУГ:** кабатлау, өйрәнү, үзләштерү, хаталарны төзәтү һәм нәтиҗә ясау характерындагы уку нигезләре формалашу.<br>**КУУГ:** үз фикереңне төгәл, тулы белдерү, аралашуда тел чараларыннан урынлы һәм грамоталы файдалану, парлап һәм төркемнәрдә эшли алу, башкаларның фикерләрен тыңлап, уртак фикергә килү.<br>**РУУГ:** регулятив бәяләү һәм коррекция. | Контроль эштә җибәрелгән хаталарны аңлап, кирәкле төзәтмәләр кертә алу, "Китап уку файдалы” дигән темага әңгәмә кора белү. | | | |
| 31 | Теркәгечләр. | Теркәгеч турында гомуми мәгълүмат бирү, теркәгеч төркемчәләре белән таныштыру, аларның сөйләмдәге һәм җөмләдәге ролен аңлату. | Буш вакытны дөрес оештыра белүнең мөһимлеген аңлау. | **ТБУУГ:** Төп мәгълүматны аеру, үтәлә торган биремнәрнең мәгънәсен аңлау, объектларны чагыштыру, классификацияләү, уртак билгеләрне таба белү.<br>**КУУГ:** укытучы һәм сыйныфташлар белән белем алу эшчәнлеген оештыру, продуктив хезмәттәшлек итү, аралашу күнекмәләре формалашу.<br>**РУУГ:** гамәлләрне бирелгән үрнәк һәм кагыйдә буенча планлаштыру, максат куя белү, башкару. | Теркәгечләрнең җөмләдәге ролен белү, аларны сөйләмдә дөрес итеп куллану, алар кергән җөмләләрне ишетеп аңлау. | | | |
| 32 | Минем буш | Буш вакыт турында | Шәхси үсеш өчен | **ТБУУГ**: конкрет шартлардан чыгып, | Теркәгечләрнең | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | вакытым. Теркәгечләрне кабатлау. | фикер алышу. Теркәгечләрнең кулланылыш үзенчәлекләре, аларның интонациягә бәйле булуы. | буш вакытны дөрес оештыруның кирәклеген аңлау. | биремнәрне үтәү өчен, нәтиҗәлерәк ысулларны сайлап алу, төшенчәләргә билгеләмә бирү, чагыштыру, классификацияләү.<br>**КУУГ**: бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү; телдән һәм язма сөйләм оештыру, төркемдә эшли белү.<br>**РУУГ**: эшчәнлекне планлаштыра, максат куя белү, куелган максатларга ирешүгә юнәлтелгән эшчәнлек белән идарә итү. | кулланылыш үзенчәлекләрен белү, буш вакыт турында сөйләшүдә катнашу. | | | |
| 33 | Исем фигыльнең барлык, юклык формасы | Исем фигыльнең исем һәм фигыль белән уртак якларын ачыклау, җөмләдә кулланылышын үзләштерү. | Кеше хезмәтенә хөрмәт, әйләнә-тирәдәгеләргә яхшы мөнәсәбәт булу. | **ТБУУГ:** төшенчәләргә билгеләмә бирү, сәбәпле-нәтиҗәле бәйләнешләр урнаштыру; өйрәнү барышында туган күренешләрне, бәйләнешләрне аңлата алу.<br>**КУУГ:** укытучы һәм сыйныфташлар белән белем алу эшчәнлеген оештыру, продуктив хезмәттәшлек итү, аралашканда сөйләм чараларын дөрес куллану, башкалар алдында чыгыш ясый алу.<br>**РУУГ:** гамәлләрнең үтәлешен мөстәкыйль рәвештә дөрес бәяли, төзәтмәләр кертә алу. | Исем фигыльнең исем һәм фигыль белән уртак якларын таба алу. | | | |
| 34 | Мөнәсәбәт белдерүче сүзләр | Кереш сүзләр турында гомуми мәгълүмат бирү, аларның җөмләдәге ролен аңлату. | Яшьтәшләргә, сыйныфташларга карата игътибарлы булу, эш-гамәлләргә карата мөнәсәбәтеңне итәгатьле итеп җиткерә белү. | **ТБУУГ:** уку мәсьәләсен чишкәндә логик фикерли алу, төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыра белү.<br>**КУУГ:** әңгәмәдәшеңнең сөйләмен тыңлый, аңлый, аңа туры килерлек сораулар бирә белү, башкаларга аңлаешлы сөйләм төзи алу.<br>**РУУГ:** хезмәттәшлектә укытучы тарафыннан билгеләнгән эш-гамәл ориентирларын исәпкә алу; эш тәртибен аңлап, нәтиҗәле эш алымнарын куллану. | Кереш сүзләрне җөмләдә аера һәм дөрес итеп куллана белү | | | |
| 35 | Файдалы, файдасыз үткәрелгән буш вакыт. | “Минем буш вакытым” дигән темага сөйләшү, хикәя язу. | Буш вакытны дөрес оештыра белү, файдасыз үткәрелгән буш вакытның зыянлы икәнен, аны файдалы үткәрергә | **ТБУУГ**: өйрәнелә торган күренешләр тирәсендә сәбәпле-нәтиҗәле мөнәсәбәтләр урнаштыру, аерым кисәклардән бербөтен төзү.<br>**КУУГ**: бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү; телдән һәм язма | “Буш вакыт” темасы буенча сөйләшүдә катнаша һәм хикәя яза алу. | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | кирәклеген аңлау. | сөйләм оештыру, парлап һәм төркемдә эшли белү.<br>**РУУГ**: эшчәнлекне планлаштыра белү, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | | | | | |
| 36 | “Ялгыш адым” шигырендәге лексик-грамматик материал. | Шәүкәт Галиевнең “Ялгыш адым” шигырендәге лексик-грамматик материал буенча эшчәнлек, сорауларга җавап бирү. | Сәламәтлекне саклау кагыйдәләрен һәм нормаларын белү. | **ТБУУГ**: укуның төрле формаларыннан файдалану (кычкырып, пышылдап, өстән-өстән, эчтәлекне аңлап), укылган мәгълүматка бәйле гади нәтиҗәләр ясау.<br>**КУУГ**: бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү, уку диалогында катнашу.<br>**РУУГ**: гомуми кагыйдәләргә һәм кабул ителгән нормаларга буйсына белү, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау. | “Ялгыш адым” шигыре буенча сорауларга җавап бирә белү, үз фикереңне белдерү һәм әңгәмәдә катнашу. | | | | |
| 37 | “Ялгыш адым” шигыре. Үрнәк сыйфатлар. | Шәүкәт Галиевның “Ялгыш адым” шигыренә караган лексик-грамматик материалны үзләштерү буенча эшне дәвам итү, әңгәмә оештыру, сорауларга җавап бирү. | Кылган гамәлләрең өчен җаваплылык хисе булу, сәламәтлекне саклау кагыйдәләрен һәм нормаларын белү. | **ТБУУГ**: текстның төп мәгънәсен аеру, укылган мәгълүматның эчтәлеген үз сүзләрең белән җиткерә белү, сурәтләнгән вакыйгаларның эзлеклелеген урнаштыру.<br>**КУУГ**: хезмәттәшлектә үз фикереңне формалаштыра, аргументлаштыра, бәхәсләшә һәм үз позицияңне яклый белү.<br>**РУУГ**: гамәлләрне бирелгән үрнәк буенча планлаштыру, башкару, аларны таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау. | Шәүкәт Галиевнең “Ялгыш адым” шигыре буенча әңгәмә кора белү, бер-береңә сораулар биргәндә, фикер алышканда лексик-грамматик материалны урынлы һәм дөрес куллана алу. | | | | |
| 38 | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. | Исемнәрнең тартым белән төрләнешен үзләштерү, аның кулланылыш һәм ясалыш үзенчәлеген аңлату. | Яшәгән урыныңа, әйләнә-тирәдәгеләргә яхшы мөнәсәбәттә булуның әһәмиятен аңлау. | **ТБУУГ**: уку мәсьәләсен чишкәндә логик фикерли алу, төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру, төшенчә чыгару, модельләштерү, төп мәгълүматны билгеләү, үрнәк буенча биремнәр эшли алу.<br>**КУУГ**: төрле коммуникатив мәсьәләләрне чишү өчен сөйләм чараларын дөрес куллану, телдән һәм язма сөйләм оештыру, монологик сөйләм күнекмәсе булу.<br>**РУУГ**: уку мәсьәләсен кабул итү һәм саклау, гамәлләрне бәяләү һәм ясалган хаталар характерын исәпкә алып, эш-гамәлләргә кирәкле төзәтмәләр кертү. | Тартымлы исемнәрнең кушымчаларын белү, сөйләмдә тартымлы исемнәрне дөрес куллана белү. | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 39 | Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнешен үзләштерү, аларның кулланылыш һәм ясалыш үзенчәлеген аңлату. | Үз-үзенә һәм башкаларга зыян китермәслек гамәлләр кылу, сәламәт яшәү рәвешенә ориентлашу. | **ТБУУГ**: төшенчәләргә билгеләмә бирү, эшчәнлек алгоритмнарын төзү, өйрәнелә торган объектларда уртак билгеләрне аерып чыгару. **КУУГ**: бирелгән коммуникатив мәсьәләләрне чишү өчен сөйләм чараларын дөрес куллану, телдән һәм язма сөйләм оештыру. **РУУГ**: бирелгән тема буенча уку мәсәләсен кабул итү һәм укытучы күрсәтмәләренә иярү, үтәлә торган биремнәрнең максатын һәм мәгънәсен аңлау. | Сөйләмдә тартымлы исемнәрне төрле килештә дөрес куллана белү. | | | |
| 40 | “Минем буш вакытым” темасы буенча мөстәкыйль эш. | “Минем буш вакытым” темасына мөстәкыйль эш эшләү. | Ял иткәндә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үтәүнең мөһимлеген аңлау. | **ТБУУГ:** уку мәсьәләсен чишү алгоритмын сайлау, тема буенча белемнәрне гомумиләштерү; эшне башкарганда биремнәрне аңлап мөстәкыйль рәвештә язма формада үтәү. **КУУГ:** үз фикереңне төгәл, тулы белдерү, карар кабул итү, сайлау алдыннан төрле фикерләрне чагыштыру һәм ачыклау; биремнәрне үтәгәндә нәтиҗәле ысулларны сайлап алу, татарча грамоталы итеп язарга омтылу. **РУУГ:** максат кую һәм эшчәнлекне нәтиҗәле оештыру. | Алган белемнәрне практикада куллана белү. | Мөстәкыйль эш | | |
| 41 | Роберт Миңнуллин-ның “Подъездлагы язулар” шигырендәге лексик-грамматик материал. | Тема буенча яңа лексик-грамматик материал бирү, әңгәмә оештыру. | Чисталыкка, матурлыкка омтылу, кылган гамәлләреңә карата җаваплылык хисе формалашу. | **ТБУУГ**: укуның төрле формаларыннан файдалану (кычкырып, пышылдап, өстән-өстән, эчтәлекне аңлап), төп мәгълүматны аеру, текстның эчтәлегенә бәйле нәтиҗәләр ясау. **КУУГ**: бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү, уртак эшчәнлектә гомуми карарлар чыгарганда аны башкалар позициясе белән килештерү. **РУУГ**: уку эшчәнлеген оештырганда гомуми кагыйдәләргә һәм кабул ителгән нормаларга буйсыну, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау. | Шигырь текстындагы лексик-грамматик материалны үзләштерү. | | | |
| 42 | Роберт | “Подъездлагы | Кеше хезмәтенә | **ТБУУГ:** эзләнү, анализ, синтез, | Тема буенча лексик- | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Миңнуллин-ның “Подъезд-дагы язулар” шигыре. | язулар” шигыре буенча коммуникатив эш төрләре. | хөрмәт, әйләнә-тирәдәгеләргә яхшы мөнәсәбәт булу. | чагыштыру, үрнәк буенча эшли алу нигезләре; текстны укып, эчтәлегенә бәя бирү, аны үз сүзләрең белән җиткерә белү, проблеманы аерып чыгарып формалаштыру, аны чишү өчен план төзү, максатка ирешү юлларын билгеләү.<br>**КУУГ:** сорауларга җавап бирә алу, аерым фикерләрне исбатлый һәм кире кага белү, тема буенча әңгәмәдә катнаша алу.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне планлаштыра белү, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | грамматик материалны дөрес кулланып, әңгәмә оештыра алу. | | | |
| 43 | “Без бергә ял итәбез” бүлеген кабатлау. Сүзлек эше. | Үтелгән темалар буенча сүзлек эше. | Үз-үзеңә һәм башкаларга зыян китермәслек гамәлләр кылу; әйткән сүзләрең һәм эш-гамәлләрең өчен җаваплылык хисе булдыру. | **ТБУУГ**: бирелгән сүзләрне кабатлау, аерым сүзләрдән җөмлә төзү, уй-фикерне сөйләм һәм язма формада әйтә белү.<br>**КУУГ**: бердәм эшчәнлектә укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү, фикерне төгәл, тулы белдерү, җөмлә төзегәндә нәтиҗәле ысулларны сайлап алу, татарча граматолы итеп сөйләшергә һәм язарга омтылу.<br>**РУУГ**: эшчәнлекне планлаштыра белү, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | Алган белемнәрне практикада куллана белү. | Сүзлек эше. | | |
| **III. Өлкәннәр һәм кечкенәләр. 16 сәг.** | | | | | | | | |
| 44 | Җөмләнең иярчен кисәкләре. Аергыч. | Җөмләнең иярчен кисәге - аергыч турында төшенчә бирү. ”Өлкәннәр һәм кечкенәләр” дигән темага сөйләшү. | Өлкәннәргә һәм кечкенәләргә игътибарлы булырга кирәклеген аңлау. | **ТБУУГ**: Логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, тәкъдим ителгән билгеләр буенча төшенчәне әйтү, өйрәнелгән объектларны кыскача характеристикалау, җөмләнең төп берәмлекләрен тамга белән билгеләү.<br>**КУУГ:** хезмәттәшлектә үз фикереңне формалаштыру, аргументлаштыру һәм уртак эшчәнлектә башкалар позициясе белән килештерү.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне планлаштыра, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | Җөмләнең иярчен кисәкләрен таба, аера белү, рус һәм татар телендәге мисаллар белән чагыштырып карау, аергыч җөмлә кисәге турында мәгълүматлы булу. ”Өлкәннәр һәм кечкенәләр” дигән темага сөйләшүдә катнаша алу. | | | |
| 45 | “Өлкәннәр һәм кечкенәләр | ”Өлкәннәр һәм кечкенәләр” | Өлкәннәргә һәм кечкенәләргә | **ТБУУГ:** текстны аңлап уку; өзектән кирәкле мәгълүматны сайлап ала һәм аның | Җөмләнең иярчен кисәкләрен таный, аера | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | мөнәсәбәте” текстына караган лексик-грамматик материал. | текстына караган лексик-грамматик материалны үзләштерү буенча эшчәнлек. | хөрмәтле мөнәсәбәт булу. | эчтәлегенә бәя бирә белү.<br>**КУУГ:** фикерне җитәрлек дәрәҗәдә тулы һәм төгәл итеп әйтә белү, коммуникатив максатлардан чыгып, сүзләрне урынлы һәм дөрес куллана белү, диалогта катнашу осталыгына ия булу.<br>**РУУГ:** уку мәсьәләсен кабул итү, укытучы күрсәтмәләренә ияру; үтәлә торган биремнәрнең максатын, мәгънәсен аңлау һәм максатка ирешү юлларын билгеләү. | белү. Тексттагы лексик-грамматик материалны урынлы һәм дөрес куллану. | | | |
| 46 | Җөмләнең иярчен кисәкләре. Тәмамлык. | Җөмләнең иярчен кисәге - тәмамлык турында төшенчә бирү, синтаксик анализ күнекмәләре булдыру өстендә эш. | Әйләнә-тирәдәгеләргә уңай мөнәсәбәттә булу, кирәк чакта ярдәмгә килә алу, үз гамәлләренә бәя бирә белү. | **ТБУУГ**: Логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, тәкъдим ителгән билгеләр буенча төшенчәне әйтү, өйрәнелгән объектларны кыскача характеристика бирү, җөмләнең төп берәмлекләрен тамга белән билгеләү.<br>**КУУГ:** хезмәттәшлектә үз фикереңне формалаштыру, аргументлаштыру һәм уртак эшчәнлектә башкалар позициясе белән килештерү.<br>**РУУГ:** җөмләнең иярчен кисәге тәмамлыкны рус һәм татар телендәге мисаллар ярдәмендә чагыштыру. | Җөмләнең иярчен кисәкләрен таба белү, тәмамлык җөмлә кисәге турында мәгълүматлы булу. ”Тәрбиялелек сыйфатлары ” дигән темага әңгәмәдә катнаша алу. | | | |
| 47 | Җөмләнең иярчен кисәкләре. Хәл. | Җөмләнең иярчен кисәге - хәл турында төшенчә бирү, синтаксик анализ күнекмәләре буенча эш. | Дуслык, хөрмәт, үзара ярдәмләшү, төшенчәләрен аңлау, башкаларга карата кайгыртучанлык, түземлелек хисләре формалашу. | **ТБУУГ**: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, тәкъдим ителгән билгеләр буенча төшенчәне әйтү, җөмләнең төп берәмлекләрен тамга белән билгеләү, өйрәнелгән объектларны кыскача характеристика бирә белү.<br>**КУУГ:** хезмәттәшлектә үз фикереңне формалаштыру, аргументлаштыру һәм уртак эшчәнлектә башкалар позициясе белән килештерү.<br>**РУУГ:** җөмләнең иярчен кисәкләрен рус һәм татар телендәге мисаллар ярдәмендә чагыштыру. | Җөмләнең иярчен кисәкләрен таба, аера белү, хәл җөмлә кисәге турында мәгълүматлы булу. | | | |
| 48 | ”Ярдәмләшеп яшәү күңелле” темасы буенча хикәя язу. | ”Ярдәмләшеп яшәү күңелле” дигән темага сөйләшү, хикәя | Гаилә кыйммәтләренә хөрмәт барлыкка килү, | **ТБУУГ**: объект, аның сыйфатлары һәм бәйләнешләре турында гади фикерләү формасында хикәя төзи алу.<br>**КУУГ**: бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат | ”Ярдәмләшеп яшәү күңелле” дигән темага сөйләшү, хикәя яза алу. | Сочинение | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | язу. | әти-әниеңнең, якыннарыңның хисләрен аңлау һәм алар белән уртаклашу, аларга ярдәм итәргә әзер булу. | алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү, фикерне төгәл, тулы белдерү, текст төзегәндә нәтиҗәле ысулларны сайлап алу, татарча граматолы итеп сөйләшергә һәм язарга омтылу.<br>**РУУГ**: эшчәнлекне планлаштыра белү, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | | | | |
| 49 | Исем фигыльнең килеш белән төрләнеше. | Исем фигыльнең килеш белән төрләнеше белән танышу, диалогик, монологик сөйләмдә куллану буенча эш. | Ата-анага, өлкәннәргә карата хөрмәт, кайгыртучанлык хисләре формалашу; ата-ана сүзен тыңлау. | **ТБУУГ**: конкрет шартлардан чыгып, биремнәрне үтәү өчен, нәтиҗәле ысулларны сайлап алу, төшенчәләргә билгеләмә бирү, чагыштыру, классификацияләү.<br>**КУУГ**: укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү; телдән һәм язма сөйләм оештыру, парлап һәм төркемнәрдә эшли белү.<br>**РУУГ**: Эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү. | Исем фигыльне җөмләдә аера һәм дөрес итеп куллана белү. | | | |
| 50 | Затланышсыз фигыльләрне кабатлау. | Затланышсыз фигыльләрнең грамматик билгеләрен искә төшерү, аларның сөйләмдә дөрес куллану күнекмәсе булдыру буенча биремнәр. | Гаилә һәм җәмгыять кыйммәтләрен белү, хөрмәт итү һәм аларны үтәүгә ориентлашу. | **ТБУУГ**: конкрет шартлардан чыгып, биремнәрне үтәү өчен, нәтиҗәле ысулларны сайлап алу, фикерләрне логик чылбырга салу, эшчәнлек нәтиҗәсен тикшерү һәм бәя бирү.<br>**КУУГ**: бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү; телдән һәм язма сөйләм оештыру, парлап һәм төркемнәрдә эшли белү.<br>**РУУГ**: регулятив бәяләү һәм коррекция. | Затланышсыз фигыльләрне дөрес кулланып, яраткан шөгылең турында диалогик һәм монологик сөйләм төзи алу. | | | |
| 51 | Контроль эш. Затланышсыз фигыльләр. | “Затланышсыз фигыльләр” темасына контроль эш башкару. | Дәрес таләпләреннән чыгып, үз эшчәнлегеңне нәтиҗәле оештыру; шәхси үсеш өчен белем алуның мөһимлеген аңлау. | **ТБУУГ:** тема буенча белемнәрне структуралаштыру, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү; эшне башкарганда биремнәрне аңлап мөстәкыйль рәвештә язма формада үтәү.<br>**КУУГ:** үз фикереңне төгәл, тулы белдерү, алган белемнәрне истә тотып эш итү, карар кабул итү, сайлау алдыннан төрле фикерләрне чагыштыру һәм ачыклау. | Алган белемнәрне практикада куллана белү. | Контроль эш | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **РУУГ:** үзрегуляция. | | | | |
| 52 | Хаталар өстендә эш. Грамматик күнегүләр эшләү. | Хаталар өстендә эш башкару. Фигыль темасын кабатлау. | Гаилә кыйммәтләренең файдасын аңлау; үзара ярдәм, эчкерсезлек, юмартлык сыйфатлары формалашу. | **ТБУУГ:** укытучы ярдәме белән алгоритм төзи һәм шуның буенча эшли белү, кабатлау, өйрәнү, үзләштерү, хаталарны төзәтү һәм нәтиҗә ясау характерындагы уку нигезләре формалашу.<br>**КУУГ:** үз фикереңне төгәл, тулы белдерү, аралашуда тел чараларыннан урынлы һәм грамоталы файдалану, башкаларның фикерләрен тыңлап, уртак фикергә килү, хезмәттәшлектә үзара ярдәмләшү.<br>**РУУГ:** регулятив бәяләү һәм коррекция. | Монологик һәм диалогик сөйләмдә фигыльләрне дөрес итеп куллана белү | | | |
| 53 | “Ата-анага хөрмәт” темасына караган лексик-грамматик материал. | ”Ата-анага хөрмәт” темасына караган лексик-грамматик материал өстендә эш | Укучыда ата-ананы олылау, хөрмәт итү хисе формалашу; ата-анага ярдәм итәргә әзер булу. | **ТБУУГ:** текстны укып, эчтәлегенә бәя бирү, аны үз сүзләрең белән җиткерә белү, проблеманы аерып чыгарып формалаштыру, аны чишү өчен план төзү, максатка ирешү юлларын билгеләү.<br>**КУУГ:** фикерне җитәрлек дәрәҗәдә тулы һәм төгәл итеп әйтә белү, монологик сөйләм төзү осталыгына ия булу.<br>**РУУГ:** уку проблемасын чишү өчен план төзү, максатка ирешү юлларын билгеләү. | “Ата-анага хөрмәт” темасына караган лексик-грамматик материал белән танышу, сөйләмдә дөрес куллана алу. | | | |
| 54 | Кисәкчәләр һәм аларның төркемчәләре. | Кисәкчәләрне (әле, инде) кулланырга өйрәнү | Туганнарга, якыннарга карата уңай мөнәсәбәттә булу, аларга ярдәм итү, үз гамәлләреңә бәя бирә белү. | **ТБУУГ:** төшенчәләргә билгеләмә бирү, сәбәпле-нәтиҗәле бәйләнешләр урнаштыру; өйрәнү барышында туган күренешләрне, бәйләнешләрне аңлату.<br>**КУУГ:** укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү, үз фикереңне төгәл, тулы белдерү, башкаларның позициясен истә тотып эш итә белү, диалогик һәм монологик сөйләм төзегәндә нәтиҗәле ысулларны сайлап алу.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне планлаштыра белү, контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү; гамәлләрне бирелгән үрнәк һәм кагыйдә буенча башкару, тикшерү. | Кисәкчәләр турында мәгълүматлы булу, аларны (әле, инде) фигыльләр белән яраклаштыра алу. | | | |
| 55 | Кисәкчәләрнең дөрес язылышы. | (да/дә, та/тә, гына/ генә, кына/кенә,, иң, бит, инде) кисәкчәләренең | Ихтирамлылык, тәрбиялелек, җаваплылык кебек төп мораль | **ТБУУГ:** кабатлау, өйрәнү, үзләштерү, хаталарны төзәтү һәм нәтиҗә ясау характерындагы уку нигезләре формалашу.<br>**КУУГ:** үз фикереңне төгәл, тулы белдерү, | Кисәкчәләрне таба һәм куллана алу, дөрес яза белү. | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | мәгънәсен һәм кулланылышын аңлату, аларны аерырга өйрәнү күнегүләре үтәү. | нормаларны белү. Кешеләргә карата сизгер булу. | аралашуда тел чараларыннан урынлы һәм грамоталы файдалану, төркемнәрдә эшли алу, башкаларның фикерләрен тыңлап, уртак фикергә килү.<br>**РУУГ:** регулятив бәяләү. | | | | |
| 56 | Кисәкчәләрнең сөйләмдә кулланылышы. | (да/дә, та/тә, гына/ генә, кына/кенә, иң, бит, инде) кисәкчәләренең кулланылышын аңлату, күнегүләр эшләү. | Ата-анага хөрмәт, сабырлык, кайгыртучанлык хисләре формалашу. | **ТБУУГ**: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, тәкъдим ителгән билгеләр буенча төшенчәне әйтү, өйрәнелгән объектларга характеристика бирә алу.<br>**КУУГ:** укытучы һәм сыйныфташлар белән белем алу эшчәнлеген оештыру, продуктив хезмәттәшлек итү, аралашу күнекмәләре формалашу.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне планлаштыра, максат куя белү, нәтиҗә ясау, эшчәнлекне контрольдә тоту, төзәтә, бәяли белү. | Кисәкчәләрне таба һәм куллана алу, дөрес яза белү. | | | |
| 57 | “Тагын бер рәхмәт” шигырендәге лексик-грамматик материал. | “Тагын бер рәхмәт” шигыренә караган лексик-грамматик материалны үзләштерү буенча эшләү. | Өлкәннәргә, әти-әниләргә карата, ярдәмчел, кайгыртучан булу. | **ТБУУГ**: укуның төрле формаларыннан файдалану (кычкырып, пышылдап, өстән-өстән, эчтәлекне аңлап), төп мәгълүматны аеру, текстның эчтәлегенә бәйле гади нәтиҗәләр ясау.<br>**КУУГ**: бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү, уртак эшчәнлектә гомуми карарлар чыгарганда аны башкалар позициясе белән килештерү.<br>**РУУГ**: гомуми кагыйдәләргә һәм кабул ителгән нормаларга буйсына белү, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау. | Өлкәннәр һәм кечкенәләр мөнәсәбәте турында сөйләшүдә катнаша, үз фикерләреңне әйтә алу. Тема буенча лексик-грамматик материалны дөрес куллану. | | | |
| 58 | “Тагын бер рәхмәт” шигыре. Билгеле һәм билгесез үткән заман хикәя фигыль. | Билгеле һәм билгесез үткән заман хикәя фигыльләрне кабатлау, шигырь лексикасы буенча эш. | Өлкәннәр һәм яшьтәшләр мөнәсәбәтләрендә, өйдә, укудан тыш эшчәлектә әхлакый кагыйдәләрне үтәргә әзер булу. | **ТБУУГ:** текстны аңлап уку; өзектән кирәкле мәгълүматны сайлап ала белү, үзләштерелгән белемнәрне куллана белү.<br>**КУУГ:** фикерне җитәрлек дәрәҗәдә тулы һәм төгәл итеп әйтә белү, коммуникатив максатлардан чыгып, сүзләрне урынлы һәм дөрес куллана белү, әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.<br>**РУУГ:** уку проблемасын чишү өчен план | Билгеле һәм билгесез үткән заман хикәя фигыльләр турында белемнәрнең актуальләшүе, сөйләмдә дөрес куллана алу, грамматик билгеләрен белү. Шигырьдәге лексиканы актив | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | төзү, максатка ирешү юлларын билгеләү. | кулланышка кертү. | | | |
| 59 | “Өлкәннәр һәм кечкенәләр” бүлеген кабатлау. Сүзлек диктанты. | Бүлекне кабатлау, үтелгән темалар буенча сүзлек эше башкару. | Өлкәннәргә, эти-әниләргә карата, ярдәмчел, кайгыртучан булу. | **ТБУУГ:** эзләнү, анализ, синтез, гомумиләштерү, нәтиҗәләр чыгару кебек уку нигезләре формалашу.<br>**КУУГ:** укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү, нәтиҗәле аралашу булдыру һәм коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү.<br>**РУУГ:** дәрес бурычларын аңлап, теманы үзләштерү буенча эшчәнлекне нәтиҗәле итеп оештыра алу. | Алган белемнәрне гамәлдә куллана белү. | Сүзлек диктанты | | |
| **IV. Без Татарстанда яшибез. 11сәг.** | | | | | | | | |
| 60 | “Туган ягым - Татарстан” темасына караган лексик-грамматик материал. | Туган ягым - Татарстан” темасына караган лексик-грамматик материал белән танышу.<br>Хаталар өстендә эш башкару. Фигыль темасын кабатлау. | Туган җиреңнең тарихи-географик образын булдыру, башка халыкларга хөрмәт формалашу. | **ТБУУГ:** текстны аңлап уку; өзектән кирәкле мәгълүматны сайлап ала белү, үзләштерелгән белемнәрне куллана белү.<br>**КУУГ:** фикерне җитәрлек дәрәҗәдә тулы һәм төгәл итеп әйтә белү, коммуникатив максатлардан чыгып, сүзләрне урынлы һәм дөрес куллана белү, диалогта катнашу осталыгына ия булу.<br>**РУУГ:** укытучы тарафыннан билгеләнгән эш-гамәл юнәлешләрен исәпкә алып, максатка ирешү шартларын мөстәкыйль рәвештә планлаштыру. | “Туган ягым - Татарстан” темасына караган лексик-грамматик материалны үзләштерү. | | | |
| 61 | Безнең туган җиребез. | Җөмлә кисәкләрен гомумиләштереп кабатлау. | Туган якның табигатенә соклану хисе, аны өйрәнү теләге барлыкка килү. | **ТБУУГ:** төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлектә куллана белү.<br>**КУУГ:** укыган яки ишеткән текст буенча сорауларга җавап бирә белү, телдән төрле типтагы монологлар, диалоглар төзү, әңгәмә кору.<br>**РУУГ:** укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү. | Җөмлә кисәкләрен аера белү, “Без туган илебез белән горурланабыз” дигән темага диалогик һәм монологик сөйләм оештыра алу. | | | |
| 62 | Татарстан Республикасы | Сыйфатларны кабатлау. Синоним, антоним сыйфатларны искә төшерү. | Туган җиргә мәхәббәт, үз илең өчен горурлык хисләре формалашу. | **ТБУУГ**: текстны аңлап уку; өзектән кирәкле мәгълүматны сайлап ала белү, тема буенча белемнәрне структуралаштыру, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү.<br>**КУУГ**: төрле коммуникатив максатларга ирешү өчен телдәге чараларны дөрес куллану, телдән һәм язма сөйләм | Сыйфатларны (синоним, антоним сыйфатларны) таба һәм куллана белү. | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | күнекмәләренә ия булу, контекстан чыгып диалог төзү.<br>**РУУГ**: укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү. | | | | |
| 63 | Сочинение. “Без Татарстанда яшибез”. | Җөмләнең баш кисәкләрен кабатлау.”Без Татарстанда яшибез” темасына сочинение язу. | Туган җиргә мәхәббәт, үз илең өчен горурлык хисләре формалашу. | **ТБУУГ:** иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы чишү ысулларын мөстәкыйль рәвештә булдыру; тиешле мәгълүматны табу өчен энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.<br>**КУУГ:** үз фикереңне төгәл, тулы белдерү, дәлилли алу, алган белемнәрне истә тотып эш итү, карар кабул итү, сайлау алдыннан төрле фикерләрне чагыштыру һәм ачыклау.<br>**РУУГ:** үзрегуляция. | Җөмләнең баш кисәкләрен таба һәм куллана белү.”Без Татарстанда яшибез” темасына монологик сөйләм төзи алу. | Сочинение | | |
| 64 | Проект. ”Без Татарстанда яшибез”. | Синтаксисны кабатлау. Җөмлә темасы буенча белемнәрне камилләштерү. | Үз илеңнең тарихи-географик образын булдыру, казанышларын, мәдәни традицияләрен белү. | **ТБУУГ**: тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.<br>**КУУГ**: төрле коммуникатив максатларга ирешү өчен, телдәге чараларны дөрес куллану; мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару.<br>**РУУГ**: Үзрегуляция. Процессны проектлау, карар кабул итү, гамәлләр тәртибен ачыклау, гамәлләрнең рациональ ысулын сайлап алу. | Җөмлә кисәкләрен таба һәм аера белү. | Проект эше | | |
| 65 | Теләк фигыль. | Теләк фигыль турында гомуми мәгълүмат бирү, аларның сөйләмдәге һәм җөмләдәге ролен аңлату. | Дусларыңа, яшьтәшләреңә ихтирам белән мөрәҗәгать итү. | **ТБУУГ**: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, тәкъдим ителгән билгеләр буенча төшенчәне әйтү, өйрәнелгән объектларны кыскача характеристикалау.<br>**КУУГ**: төрле коммуникатив максатларга ирешү өчен телдәге чараларны дөрес куллану, телдән һәм язма сөйләм күнекмәләренә ия булу.<br>**РУУГ**: укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү. | Теләк фигыльләрне җөмләдә аера һәм дөрес итеп куллана белү. | | | |
| 66 | “Кешегә һәрвакыт яхшыдан-яхшы | “Кешегә һәрвакыт яхшыдан-яхшы | Кеше шәхесенә, аның | **ТБУУГ:** текстны аңлап уку; өзектән кирәкле мәгълүматны сайлап ала белү, | Һәрвакыт яхшылыкка омтылу турында | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | кирәк” тексты. | кирәк” тексты буенча эшчәнлек, газетага мәкалә язу. | казанышларына хөрмәт хисе барлыкка килү. | укылган текстның эчтәлегенә бәя бирә белү, үзләштерелгән белемнәрне куллана белү.<br>**КУУГ:** фикерне җитәрлек дәрәҗәдә тулы һәм төгәл итеп әйтә белү, сөйләмдә сүзләрне урынлы һәм дөрес куллана белү, әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү.<br>**РУУГ:** уку проблемасын чишү өчен план төзү, максатка ирешү юлларын билгеләү. | сөйләшүдә катнашу, мәкалә яза алу. | | | |
| 67 | Максатны белдерү формалары. Грамматик күнегүләр эшләү. | Үтелгән темаларны кабатлау һәм ныгыту. | Үзеңне халык вәкиле, Россия гражданины буларак тану һәм гомуми тормыш дәрәҗәсе өчен һәр кешенең җаваплылыгын аңлау. | **ТБУУГ:** текст белән эшләү, эзләнү, анализ, синтез, гомумиләштерү, нәтиҗәләр чыгару кебек уку нигезләре формалашу.<br>**КУУГ:** бердәм эшчәнлек яки мәгълүмат алышу буенча укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү, коммуникатив рефлексияне гамәлгә ашыру.<br>**РУУГ:** дәрес бурычларын аңлап, теманы үзләштерү буенча эшчәнлекне нәтиҗәле итеп оештыра алу. | Сүз төркемнәрен аера белү, җөмлә кисәкләрен таба һәм аера белү. | | | |
| 68 | Еллык контроль эш. Сүз төркемнәре. | Еллык контроль эш башкару. | Башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык хисләре формалашу, мәктәп таләпләрен, укучы бурычларын үтәргә әзер булу. | **ТБУУГ:** тема буенча белемнәрне структуралаштыру, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү; эшне башкарганда биремнәрне аңлап мөстәкыйль рәвештә язма формада үтәү.<br>**КУУГ:** үз фикереңне төгәл, тулы белдерү, дәлилли алу, башкаларның позициясен истә тотып эш итү, карар кабул итү, сайлау алдыннан төрле фикерләрне чагыштыру һәм ачыклау.<br>**РУУГ:** үзрегуляция. | Алган белемнәрне практикада куллана белү. | Контроль эш | | |
| 69 | Хаталар өстендә эш. Грамматик күнегүләр эшләү. | Үткән материалны кабатлау һәм ныгыту. ”Казан-Татарстанның башкаласы” дигән темага сөйләшү. | Үз илең, халкың, тарихың белән горурлану хисләре формалашу. | **ТБУУГ:** кабатлау, өйрәнү, үзләштерү, хаталарны мөстәкыйль табу, төзәтмәләр кертү һәм нәтиҗә ясау характерындагы уку нигезләре формалашу.<br>**КУУГ:** үз фикереңне төгәл, тулы белдерү, аралашуда тел чараларыннан урынлы һәм грамоталы файдалану, парлап һәм төркемнәрдә эшли алу, башкаларның фикерләрен тыңлап, уртак фикергә килү.<br>**РУУГ:** регулятив бәяләү һәм коррекция. | Тел турында белемнәрне системага салу, ”Казан-Татарстанның башкаласы” дигән темага сөйли белү. | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 70 | Үткәннәрне кабатлау, йомгаклау. | Сүз төркемнәрен гомумиләштереп кабатлау, ел дәвамында алган белемнәрне ныгыту. | Мәктәпкә, телне өйрәнүгә уңай караш формалашу; үз мөмкинлекләреңне, булдыра алганлыгыңны, шәхси сыйфатларыңны аңлый белү. | **ТБУУГ:** кабатлау, өйрәнү, үзләштерү, нәтиҗә ясау характерындагы уку нигезләре формалашу.<br>**КУУГ:** үз фикереңне төгәл, тулы белдерү, аралашуда тел чараларыннан урынлы һәм грамоталы файдалану, парлап һәм төркемнәрдә эшли алу, башкаларның фикерләрен тыңлап, уртак фикергә килү.<br>**РУУГ: үз**регуляция. | Үтелгән белемнәрне системага салу;<br>сүз төркемнәрен тексттан аерып курсәтә белү, төп грамматик билгеләрен әйтә алу, сөйләмдә актив куллана алу. | | | |

**Рус телендә гомуми төп белем бирү мәктәпләрендә татар телен өйрәнүче укучылар өчен (VII сыйныф) татар әдәбиятыннан эш программасы**

(Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). 7 нче с-ф. Ике кисәктә / Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Г.Г. Мулласалихова. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2014. дәреслеге буенча)

Т ө з ү ч е - а в т о р л а р ы :

Сәфиуллина Г.И., Казан шәһәре 117 нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Ногманова А.И., Казан шәһәре 91 нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Сафина Г.Х., Казан шәһәре 96 нчы гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Закирова А.Х., Казан шәһәре 96 нчы гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Аңлатма язуы**

7 нче сыйныфның рус төркеме өчен татар әдәбиятыннан эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелде:

1. Россия Федерациясенең «Мәгариф турында»гы Законы (Федеральный закон от 29.12.2012 273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации»).
2. Татарстан Республикасының «Мәгариф турында»гы Законы (Закон Республики Татарстан «Об образовании» № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года, статья 8).
3. Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе халык телләре турында»гы 126-ФЗ нчы номерлы Законы (24.07 1998).
4. «2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы», 2013 нче ел, 25 нче октябрь, 794 нче карар.
5. Төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандарты (Россия Мәгариф һәм Фән министрлыгында 19644 нче регистрацион номеры белән 2011 нче елның 1 нче февралендә теркәлгән).
6. Татарстан Республикасында 2012-2020 нче елларда фән һәм мәгариф үсеше турында «Дәүләт программасы».
7. Төп гомуми белем бирү мәктәпләре өчен рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы. Төзүче авторлары: Ә.Р. Мотыгуллина, Р.Г. Ханнанов, Г.Г. Мулласалихова, Э.Х. Гыйзәтуллина. – Казан: «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты, 2015. (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән).
8. Белем бирү учреждениесенең укыту планы.

Эш программасы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән “Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре (V-VII сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан авторлык программасы”на (Төзүче-авторлары: А.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Л.К.Хисмәтова, Э.Х.Гыйзәтуллина, Г.Г.Мулласалихова). – Казан, 2014), 7 нче сыйныф өчен Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Г.Г. Мулласалихова эшләгән (Казан: "Мәгариф-Вакыт" нәшр., 2014) Татарстанның Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслеккә нигезләнеп төзелде.

Дәреслек: Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). 7 нче с-ф. Ике кисәктә / Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Г.Г. Мулласалихова. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2014.

**Федераль дәүләт белем бирү стандартларына таянып, рус телендә сөйләшүче балаларга татар әдәбиятын өйрәнүнең максаты** – туган халкының һәм җирле халыкның телен, мәдәниятен, әдәбиятын яхшы белгән, һәрьяктан камил, милли горурлык хисләре үскән шәхес тәрбияләү.

**Әлеге максатны тормышка ашыру өчен түбәндәге бурычлар куела:**

- Татарстан төбәгендә яшәп, җирле халык белән аралашкан укучыларны төбәкнең әдәби-мәдәни байлыгы белән якыннан таныштыру;
- татар әдәбияты турындагы мәгълүматларны төрле халык фольклоры, әдәбияты, мәдәнияте, милли образлары белән чагыштырма аспектта бирү;
- татар халык авыз иҗаты турында тулы күзаллау булдыру, аны баланың үз туган халкының рухи җәүһәрләре белән чагыштырырга күнектерү; әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен төшендерү;
- татар әдипләре, сәнгать әһелләре турында күзаллау булдыру, аларны танырга, иҗатларын аңларга, башка халыкларның сүз сәнгатен, культурасын үстерүчеләр белән чагыштырма планда бәяләргә өйрәтү;
- татар, рус, Россиядә яшәүче башка халыклар, бөтендөнья әдәбияты белеме казанышларының уртак нигезен аңлау, аларны үстерү һәм киңәйтү;
- алган белем һәм күнекмәләрен тормышта куллана белергә, үз юлын сайларга әзерләү; укучыларда кешелеклелек, горурлык һәм үз кадереңне белү хисләрен тәрбияләү;
- Ватанны яратырга өйрәтү; гражданлык хисләре һәм ватанпәрвәрлек тәрбияләү.

Татарстан Республикасының белем бирү системасына куйган төп бурычы – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле һәм ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы билингваль (полилингваль) шәхес тәрбияләү.

**Укыту предметының укыту планында тоткан урыны**

Мәктәпнең укыту планында каралганча, татар әдәбияты дәресләре өчен атнага – 2 сәгать исәбеннән елга 70 сәгать бирелә.

**Планлаштырыла торган нәтиҗәләр**

- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау;
- классик әдипләрнең биографик белешмәләре белән танышу;
- өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм бәяләү;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча план төзү;
- әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
-укыган әсәрнең темасын, проблемасын билгеләү;
- геройларга характеристика бирү;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү;
- әсәрне сәнгатьле итеп уку;
- кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
- өйрәнелгән әсәрләргә бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү;
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикереңне дәлилли белү;
- аерым автор, аның әсәре, гомумән, әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, интернет чаралары һ.б. аша эзләү.

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- туган илгә мәхәббәт, ватанпәрвәрлек хисләре, туган телгә сакчыл караш булу;
- укуга теләк-омтылыш, җаваплылык белән карый белү;
- әйләнә-тирә табигатькә дөрес карашлы булу;
- кешеләр белән аралаша белү культурасына ия булу;
- гаделлек, дөреслек, яхшылык, мәрхәмәтлелек һ.б. сыйфатлар һәм аларның киресе булган сыйфатларны таный, бәяли алу;
- алган белем һәм осталыкны тормышта максатчан кулланырга өйрәнү.

**Метапредмет нәтиҗәләре:**

- текстны дөрес аңлап уку һәм бәяләү;
- билгеләрне аерып чыгару максаты белән объектларны анализлау;
- дөрес нәтиҗәләр чыгару, гомумиләштерү;
- сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен билгеләү;
- үз фикереңне исбатлый һәм яклый алу;
- иптәшеңне тыңлый, ишетә белү, ишеткәнен үз фикере белән чагыштыра алу;
- үз фикереңне телдән һәм язма формада башкаларга җиткерә белү;
- төркемнәргә берләшү, бер фикергә килә белү;
- өлкәннәр һәм яшьтәшләрең белән продуктив уртак гамәл оештыра белү;
- дәреснең темасын, проблемасын, максатын мөстәкыйль тәгъбир итә алу;
- план буенча эшли белү;
- үзконтроль һәм үзбәя нигезләрен үзләштерү, уку һәм танып-белүдә аңлы рәвештә сайлап ала белү.

**Предмет нәтиҗәләре:**

- төрле стильдәге һәм жанрдагы текстларны аңлап укый белү, текстның асыл мәгънәсен аңлау;
- әдәби әсәргә бәя биргәндә, элементар әдәби терминологиядән файдалана белү;
- геройларга характеристика бирү, төрле әсәрдәге бер яки берничә герой белән чагыштыра белү;

- авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, әсәрне өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;
- татар әдәбиятының һәм тарихи мәгълүматларның дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;
- авторларның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллаулы булу;
- сүзлекләр, энциклопедияләр, Интернет-ресурслардан файдаланып, үзенә кирәкле материалны таба алу;
- төрле темаларга проект эше яклый алу;
- әдәби әсәрне тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирә белү.

## 2. Курсның эчтәлеге

| № | Төп темалар | Сәг. саны | Теманың кыскача эчтәлеге | Дәрес формасы | Төп эшчәнлек төрләре |
|---|---|---|---|---|---|
| **Халык әйтсә — хак әйтә (7 сәгать)** | | | | | |
| 1 | Халык авыз иҗаты. Йола фольклоры | 1 | Йола фольклоры турында төшенчә. Йолаларның төрләре. Алар – халыкның рухи байлыгы, халыкны милләт итеп берләштерә торган асыл нигезләрнең берсе. Аларның көнкүреш һәм дини гореф-гадәтләр белән бәйләнеше, төрләре, үзенчәлекләре | Дәрес-түгәрәк өстәл | Йолалар турында мәгълүмат алу; укытучы сөйләвен тыңлау, сорауларга җавап бирү, әңгәмәдә катнашу |
| 2 | Гаилә йолалары | 1 | «Бәби туе», «Туй» йолалары турында белешмә. Аларны үткәрү тәртибе | Дәрес-презентация | Гаилә йолалары белән таныштыру; текст белән эшләү, әңгәмәдә катнашу |
| 3 | Ф.Бурнаш. «Яшь йөрәкләр» | 1 | Фәтхи Бурнаш турында белешмә. «Яшь йөрәкләр» драмасы (өзек). Драмада йолаларның бирелеше, халкыбызга хас сыйфатлар | Дәрес-эзләнү | Язучы турында укытучының сөйләвен тыңлау, әсәрне рольләргә бүлеп уку, сорауларга җавап бирү, идея-проблематикасын ачыклау |
| 4 | Календарь йолалар | 1 | Төрле милләтләрнең милли йолалары турында мәгълүмат бирү | Дәрес-эзләнү | Төрле милләтләрнең милли йолалары турында мәгълүмат туплау, укылган текстның эчтәлегенә нигезләнеп, кирәкле мәгълүматны җиткерә алу |
| 5 | Бәетләр | 1 | Бәетләрнең лиро-эпик жанр булуы. «Сак-Сок» бәете. Кошларга әйләнгән ике бала язмышының фаҗигасе, бәетнең фантастик сюжетка корылган булуы | Дәрес-эзләнү | Бәетләр турында белешмә бирү, «Сак-Сок» бәетен уку, эчтәлеген сөйләү, сорауларга җавап бирү рәвешендә анализлау |
| 6 | Мөнәҗәтләр | 1 | Мөнәҗәтләрнең лирик жанр булуы, аларның нигезендә ялгызлыкта үз-үзең белән сөйләшү, Илаһи көчкә мөрәҗәгать итү, ялварып, ярлыкауны сорау икәнлеге турында мәгълүмат. Мөнәҗәтләрнең борынгы заманнардан ук татар язма әдәбиятының һәм халык иҗатының үзенчәлекле жанры булып формалашуы. «Туган ил исемнән китмәс» мөнәҗәтендә туган ил темасының бирелеше | Дәрес-презентация | Мөнәҗәтләр тыңлау, текстны аңлап уку, мөнәҗәтнең төп идеясен билгеләү, хис төшенчәсен аңлау, парларда эшләү |
| 7 | Г. Тукай. «Милли моңнар» | 1 | Габдулла Тукай иҗаты турында белешмә. «Милли моңнар» шигыре. Шагыйрь һәм милләт язмышы мәсьәләсе | Дәрес-презентация | Габдулла Тукай биографиясе буенча хронологик таблица төзү, шигырьне уку, хис-кичерешләргә, лирик геройга бәя бирү, шигырьне ятлау |
| **Аталар сүзе – акылның үзе (13 сәгать)** | | | | | |
| 8-9 | Ф. Әмирхан. «Ай өстендә Зөһрә кыз» | 2 | Фатих Әмирханның тормышы һәм иҗади эшчәнлеге. «Ай өстендә Зөһрә кыз» әсәренең татар халык әкиятләренә нигезләнүе. Яхшылык белән явызлык көрәше. Әдәбият теориясе: әдәбиятта фольклоризм | Дәрес-дискуссия | Фатих Әмирхан тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүматны истә калдыру, текстны өлешләргә, кисәкләргә аеру, төп фикерне билгеләү, төшенчәгә билгеләмә бирү |
| 10 | Н. Исәнбәт. «Җирән Чичән | 1 | Язучы Нәкый Исәнбәт иҗаты турында белешмә. Халык авыз иҗатын җыюдагы хезмәтләре. «Җирән чичән белән | Дәрес-эзләнү | Укытучы сөйләвен тыңлау, драма әсәрен рольләргә бүлеп уку, персонажларга |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | белән Карачәч Сылу» | | Карачәч сылу» драмасы. Үзәк геройда халык авыз иҗатыннан килә торган сыйфатларның (җорлык, тапкырлык, акыл көче ярдәмендә дошманнарын җиңү) туплап бирелеше | | характеристика бирү, сорауларга җавап бирү, әңгәмәдә катнашу |
| 11 - 13 | Г. Ибраһимов. «Алмачуар» | 3 | Г. Ибраһимовның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. «Алмачуар» хикәясе. Хайваннарга карата миһербанлылык хисләре тәрбияләү. Татар халкының бәйрәмнәре | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү, дәрес-дискуссия | Г.Ибраһимовның тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат алу, текстны аңлап уку, вакыйгаларны аера белү, өлешләргә исем бирү |
| 14 | Татар халкының милли киемнәре һәм бизәнү әйберләре | 1 | Түбәтәй (кәләпүш), калфак, читек, чулпы, беләзек, изү турында мәгълүмат. Милли киемнәрнең үзенчәлеге, вакыт узган саен үзгәрүләргә бирелүе, халкыбыз үткән зур тормыш юлын, аның үткәнен һәм бүгенгесен чагылдыруы | Дәрес-презентация | Презентация карау, монологик сөйли белү, проект төзү |
| 15 | Б.С.Ү. «Ат токымнары» | 1 | Монологик сөйли белү. Укылган әсәрнең эчтәлеге буенча инша язу | Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе | Монологик төзү, укылган әсәрнең эчтәлеге буенча инша язу |
| 16 | Д.Т.У. К.Васин. «Җыр шулай туды» | 1 | Ким Васинның «Җыр шулай туды» әсәре. Әсәрнең идея-проблематикасы | Дәрестән тыш уку дәресе | Әсәрне чылбыр буенча уку, төп герой турындагы мәгълүматны аерып сөйләү, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү |
| 17 | Р.Миңнуллин. «Килен төшкәндә» | 1 | Шагыйрь Р.Миңнуллин турында белешмә. «Килен төшкәндә» шигыре. Халкыбызның гореф-гадәтләрен белү, аларга мәхәббәт тәрбияләү | Дәрес-презентация | Р.Миңнуллин тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат алу, шигырьне сәнгатьле уку, сорауларга җавап бирү, килен төшү йоласы турында сөйләшү |
| 18 | Композитор Рөстәм Яхин | 1 | Композиторның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Аның профессиональ җырлар, романслар, музыкаль әсәрләр башкаруындагы эшчәнлеге. Рөстәм Яхин – Татарстан Республикасының Дәүләт гимны авторы | Дәрес-презентация | Р.Яхин тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүматны истә калдыру, диалог төзү, әңгәмәдә катнашу, музыка әсәрләрен тыңлау |
| 19 | Х. Мөдәррисова. «Көмеш дага» | 1 | Халисә Мөдәррисованың тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. "Көмеш дага" шигырендә бәхет төшенчәсенең тирән фәлсәфәсен ачуы. Сугыш фаҗигасенең чагылышы | Дәрес-эзләнү | Шагыйрә Халисә Мөдәррисова тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу, лирик герой кичергән хисләрне күрә белү, шигырьнең идеясен ачыклау |
| 20 | Б.С.Ү. «Халык авыз иҗатының әдәбиятта чагылышы» | 1 | «Халык авыз иҗатының әдәбиятта чагылышы» темасына сөйләшү | Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе | Монолог төзү, әңгәмәдә катнашу, сорауларга җавап бирү |
| **Ил язмышы – ир язмышы (13 сәгать)** | | | | | |
| 21 | Ә. Маликов. «Ил язмышы – ир язмышы» | 1 | Шагыйрь Әдип Маликов турында белешмә. «Ил язмышы – ир язмышы» шигырендә ватанпәрвәрлек билгеләре чагылу. Шигырьдә оптимистик рух. Әдәбият теориясе: гражданлык лирикасы. Пафос | Дәрес-эзләнү | Әдип Маликовның тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүматны истә калдыру, «Ил язмышы – ир язмышы» шигырен өйрәнү, Гражданлык лирикасы, пафос турындагы төшенчәләрне үзләштерү |
| 22 | Г. Кутуй. «Сагы- | 1 | Гадел Кутуйның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. | Дәрес-дискуссия | Укытучы сөйләвен тыңлау, язучы биографиясе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | ну» | | «Сагыну» нәсере. Сугыштагы кешенең кичерешләрендә туган ил образы.<br>Әдәбият теориясе: нәсер турында төшенчә. Инверсия | | буенча хронологик таблица төзү, нәсерне уку, сөйләү, анализлау, төшенчәләргә билгеләмә бирү |
| 23<br>-<br>24 | С.Хәким иҗаты. «Бакчачылар», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» | 2 | Шагыйрь Сибгат Хәкимнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. «Бакчачылар» поэмасы, «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» шигыре. Әсәрләрдә лиризм, сәнгатьчә гадилек һәм осталык, ватанпәрвәрлек хисләре чагылышы | Дәрес-эзләнү | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә алу, чылбыр буенча сәнгатьле уку, эчтәлек буенча фикер алышу, шигырьгә анализ ясау |
| 25<br>-<br>27 | Р.Төхфәтуллин. «Җиләкле алан-нар» | 3 | Язучы турында белешмә. «Җиләкле аланнар» повестенда балачак хатирәләренең самимилеге, төгәллеге. Мәктәп тормышының үзенчәлекле детальләрдә чагылышы. Укучы һәм укытучы мөнәсәбәтләрен бала күңеле һәм хисләре аша тасвирлау | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү | Р.Төхвәтуллинның тормыш юлы,<br>иҗаты турында мәгълүматны истә калдыру,текстны уку,төп вакыйгаларны сөйләү, әсәрне өлешләп анализлау, биремнәр үтәү |
| 28 | Д.Т.У. Г. Рәхим. «Буыннар елъязмасы» | 1 | Гәрәй Рәхимнең «Буыннар елъязмасы» шигыре белән танышу | Дәрестән тыш уку дәресе | Шигырьне сәнгатьле уку, эчтәлек буенча фикер алышу, шигырьгә анализ ясау |
| 29<br>-<br>30 | М.Мәһдиев. «Без – кырык беренче ел балалары» | 2 | Язучы турында белешмә. «Без – кырык беренче ел балалары» повесте (өзек). Бөек Ватан сугышы авырлыкларының әсәрдә чагылышы. Яшүсмерләр образы.<br>Әдәбият теориясе: тартмалы композиция | Дәрес,<br>дәрес-дискуссия | Укытучы сөйләвен тыңлау, язучы биографиясе буенча хронологик таблица төзү, текстны өлешләргә, кисәкләргә аеру, төп фикерне билгеләү. Тартмалы композиция турындагы төшенчәне үзләштерү, текстны уку, төп фикерне билгеләү |
| 31 | Скульптор А.Әбдрәшитов | 1 | Скульптор А.Әбдрәшитов турында белешмә | Дәрес-презентация | Скульптор А.Әбдрәшитов турында мәгълүмат алу, презентация карау, диалог төзү |
| 32 | М.Мирза. «Ике сукмак» | 1 | Шагыйрь турында белешмә. «Изге сукмак» шигыре. Балачак хатирәләренең онытылмавы, кешелеклелек сыйфатларының (мәрхәмәтлелек, изгелек, шәфкатьлелек) бирелеше | Дәрес-эзләнү | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә алу,<br>шигырьне сәнгатьле уку, эчтәлек буенча фикер алышу, шигырьгә анализ ясау |
| 33 | Д.Т.У. М. Шабаев. «Күңелемә, әткәй, кайтып кер...» | 1 | «Күңелемә, әткәй, кайтып кер...»шигыренең темасын ачу | Дәрестән тыш уку дәресе | Шигырьне сәнгатьле уку, лирик геройга бәя бирү, сорауларга җавап бирү, диалог төзү |
| **Һәр чорның үз герое (8 сәгать)** | | | | | |
| 34 | Н.Думави. «Беренче кар» | 1 | Н.Думавиның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. «Беренче кар» шигыре. Табигатьнең матурлыгын тасвирлау | Дәрес,<br>дәрес-презентация | Укытучы сөйләвен тыңлау, шигырьне сәнгатьле укый белү, эчтәлеге буенча әңгәмә дщ катнашу, биремнәр үтәү |
| 35<br>-<br>36 | Һ.Такташ. «Алсу» | 2 | Һ.Такташның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. «Алсу» поэмасы. Яшәү шатлыгы, оптимизм, үзеңне бәхетле тою хисләре чагылышы.<br>Әдәбият теориясе: рефрен, кабатлау | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, сәнгатьле уку, геройларга характеристика бирү |
| 37 | Б.С.Ү. Дустыма хат | 1 | Хат язу үрнәге белән танышу | Бәйләнешле сөйләм | Хат язу планы белән танышу, план буенча хат язу |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | язу | | | үстерү дәресе | |
| 38-39 | Х.Туфан «Агыла да болыт агыла», «Тамчылар ни диләр» | 2 | Х.Туфанның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. «Агыла да болыт агыла», «Тамчылар ни диләр?» шигырьләре. Чор белән бәйле шәхес фаҗигасе, хаксызга рәнҗетелгән кешеләр язмышы | Дәрес -эзләнү, дәрес-дискуссия | Укылган текстның эчтәлегенә нигезләнеп, кирәкле мәгълүматны җиткерә алу, шигырьне сәнгатьле уку, лирик геройны автор белән чагыштыру |
| 40-41 | Г. Тавлин. «Кояш болытка кергәндә» | 2 | Гурий Тавлинның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. «Кояш болытка кергәндә» романы (өзек). Әсәрдә фаҗигале елларның чагылышы. Чорның гаделсезлеген үз җилкәсендә татыган бала образы | Дәрес-эзләнү | Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, хикәяне аңлап уку, анализлау, биремнәрне үтәү |
| **Туган җир ул бер генә, Туган җирнең кадерен бел генә! (13 сәгать)** | | | | | |
| 42-44 | А. Гыйләҗев. «Өч аршын җир» | 3 | Аяз Гыйләҗевның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. "Өч аршын җир" повестеннән өзек. Туган җирнең кадерле булуы. Читтә яшәүчеләрнең туган туфракка тартылуы | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү, дәрес-дискуссия | Укытучы сөйләвен тыңлау, язучы биографиясе буенча хронологик таблица төзү, хикәяне уку, анализлау, хис-кичерешләргә, геройларга бәя бирү, кеше образларын (төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар) күрү, аеру. Сурәтләү чараларын табу |
| 45-47 | И. Юзеев. «Ак калфагым төшердем кулдан» | 3 | Шагыйрь Илдар Юзеев турында белешмә. «Ак калфагым төшердем кулдан...» драмасы. Чит илләрдәге милләттәшләребез язмышы. Әдәбият теориясе: ремарка | Дәрес-эзләнү, дәрес-дискуссия | Илдар Юзеевның тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүматны истә калдыру, драманы рольләргә бүлеп уку, чит илләрдә яшәүче татарлар турында мәгълүмат бирү, ремарка төшенчәсен үзләштерү, монологик сөйләм төзү |
| 48 | Б.С.Ү. Г.Зәйнәшева «Үз илемдә» | 1 | Татар җырлары белән танышу. Г.Зәйнашеваның «Үз илемдә» җыры | Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе | «Үз илемдә» җырын тыңлау, шигырьне сәнгатьле уку,лирик геройның хисләрен ачыклау, диалог төзү |
| 49 | Әлфия Авзалова иҗаты | 1 | Татар халкының бөек җырчысы Әлфия Авзалова турында белешмә, аның җырларын тыңлау | Дәрес-презентация | Әлфия Авзалова иҗаты белән танышу, укылган текстның эчтәлегенә нигезләнеп, кирәкле мәгълүматны җиткерү, фильм карау, җырлар тыңлау |
| 50 | Ф. Сафин. «Туган җиремә» | 1 | Шагыйрь Фәннур Сафин турында белешмә. «Туган җиремә» шигыре. Туган якны ярату хисләренең бирелеше | Дәрес-эзләнү | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә алу, сәнгатьле уку, эчтәлек буенча фикер алышу, ачкыч сүзләргә таянып кечкенә хикәя язу, җыр тыңлау |
| 51-54 | М.Галиев. «Нигез» | 4 | Марсель Галиевның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. «Нигез» повесте (өзек). Әсәрдә Бөек Ватан сугышы елларындагы вакыйгалар. Повестьта гореф-гадәтләрнең, йолаларның бирелеше. Туган җирнең, туган нигезнең кадерле, изге булуы, образларның бирелеше. | Дәрес-эзләнү, дәрес-презентация,дәрес-дискуссия | Укытучы сөйләвен тыңлау, язучы биографиясе буенча хронологик таблица төзү, текстны уку, аннан кирәкле мәгълүматны табу, Давыт образына характеристика бирү, повесть турында теоретик төшенчәне уку, сынландыру төшенчәсен |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Әдәбият теориясе: повесть | | искә төшерү, тексттан сынландыруларны табу |
| **Актыкта хаклык җиңә (10 сәгать)** | | | | | |
| 55-56 | Ф. Хөсни. «Сөйләнмәгән хикәя» | 2 | Фатих Хөснинең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Сөйләнмәгән хикәя” әсәре. Баланың күңел дөньясын сурәтләүдә язучының осталыгы. Мавыгу төшенчәсенә салынган мәгънәне ачыклау, үзеңә-үзең хуҗа булуның мөһимлеге.<br>Әдәбият теориясе: тема турында төшенчә | Дәрес-эзләнү, дәрес-дискуссия | Фатих Хөсни иҗаты буенча мәгълүмат бирү, текстны уку, өлешләргә бүлү, төп фикерне билгеләү , тема төшенчәсен үзләштерү, әсәрнең темасын ачыклау |
| 57-58 | Р. Хафизова. «Әти кайткан көн» | 2 | Язучы Роза Хафизова турында белешмә. «Әти кайткан көн» хикәясе. Бөек Ватан сугышы чорында балалар язмышы | Дәрес-эзләнү, дәрес-дискуссия | Язучы турында сөйләү, әсәрне уку, темасын билгеләү, укылган текстның эчтәлегенә нигезләнеп, кирәкле мәгълүматны җиткерә алу, идея турындагы теоретик төшенчәне уку, хикәянең идеясен табу |
| 59-60 | Ф.Яруллин. «Ак төнбоек» | 2 | Ф.Яруллинның «Ак төнбоек» хикәясе. Кешегә яхшылык эшләүнең күркәм гадәт икәнен, әмма аны һәрчак искә төшереп торуның кире тәэсир ясавын оста күрсәтү | Дәрес-эзләнү, дәрес-дискуссия | Әсәрне чылбыр буенча уку, эчтәлеге буенча әңгәмәдә катнашу, укытучы сорауларына җавап бирү, әсәр геройлары турында фикерләр әйтү, әсәрнең сюжетын үзгәртеп, яңа хикәя төзү,чагыштыру төшенчәсен искә төшерү, тексттан чагыштырулар табу |
| 61 | Д.Т.У. Ф. Садриев. «Юкка көттеләр» | 1 | Ф.Садриевның «Юкка көттеләр» хикәясе, күчерелмә мәгънәдә бирелгән сүзләрне аңлау | Дәрестән тыш уку дәресе | Әсәрне уку, анализлау, биремнәрне үтәү, тексттан күчерелмә мәгънәле сүзләрне табу |
| 62 | Б.С.Ү. Р. Корбан иҗаты. «Ярдәм итик» | 1 | Шагыйрь Рафис Корбан турында белешмә. «Ярдәм итик» шигыре. Бал кортлары образы мисалында хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү | Дәрес-эзләнү | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә алу, шигырьне уку, эчтәлеген сөйләү, идеясен билгеләү |
| 63 | Р. Галиуллин. «Биш «икеле» | 1 | Язучы Рөстәм Галиуллин турында белешмә. «Биш «икеле» хикәясе. Укуга, белем алуга уңай мөнәсәбәт тәрбияләү, кимчелекләрне юмор аша күрсәтү | Дәрес-эзләнү | Яшь язучының иҗаты белән танышу, укылган текстның эчтәлегенә нигезләнеп, идеяне билгеләү |
| 64 | А. Әхмәтгалиева «Табыш» | 1 | Язучы Айгөл Әхмәтгалиева турында белешмә. «Табыш» хикәясе. Бала психологиясенең бирелеше, күркәм сыйфатлар тәрбияләү. Табылган әйбернең шатлык китермәвен аңлау | Дәрес-эзләнү | Язучының иҗаты турында мәгълүматны истә калдыру, текстны өлешләргә, кисәкләргә аеру, төп фикерне билгеләү, тексттагы диалогны рольләргә бүлеп уку |
| **Табигатькә дә табиб кирәк (5 сәгать)** | | | | | |
| 65 | М.Әгъләмов. «Сөйли ак каен» | 1 | Шагыйрь М.Әгъләмов турында белешмә. «Сөйли ак каен... » шигыре. Җанландырылган табигать образлары. Экологик тәрбия бирү | Дәрес-дискуссия | Укытучы сөйләвен тыңлау, ,шигырьне сәнгатьле уку, темасын, идеясын табу, проблеманы билгеләү, лирик геройның хис-кичерешләрен билгеләү, каен агачы турында монологик сөйләм формалаштыру |
| 66 | З. Мансуров. «Балык кычкыруы» | 1 | Шагыйрь Зиннур Мансуров турында белешмә. «Балык кычкыруы» шигыре. Елга-күлләребезнең пычрануы – | Дәрес-дискуссия | Зиннур Мансуров иҗаты буенча кыскача мәгълүмат алу, шигырьләрен сәнгатьле уку, |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | кешелек дөньясы өчен зур фаҗига. Табигатькә сакчыл караш тәрбияләү | | тематикасын ачу, сорауларга җавап бирү |
| 67 | Д.Т.У. Г. Бәширов. «Җидегән чишмә» | 1 | Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» повесте. Әсәрнең төп идеясе. | Дәрестән тыш уку дәресе | Укылган текстның эчтәлегенә нигезләнеп, кирәкле мәгълүматны җиткерә алу, «Чишмәләр – яшәеш чыганагы» дигән темага хикәя язу |
| 68 | Х.Ибраһим. «Ка-рач» | 1 | Язучы турында белешмә. «Карач» хикәясе. Кешеләрнең табигатьтәге җан ияләренә мөнәсәбәте | Дәрес | Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә алу, хикәяне уку, эчтәлеген сөйләү, сорауларга җавап бирү аша анализлау |
| 69 | Б.С.Ү. «Татар халкының моңлы сандугачлары» | 1 | Татар җырчылары – Сара Садыйкова, Зөһрә Сәхәбиева турында әңгәмә | Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе | Сара Садыйкова һәм Зөһрә Сәхәбиева турында презентация карау, җырлар тыңлау, диалог төзү |
| | | | **Еллык кабатлау (1 сәгать)** | | |
| 70 | Еллык кабатлау | 1 | Еллыкка йомгак ясау | Дәрес-түгәрәк өстәл | Өйрәнгән материалны кабатлау, әңгәмәдә катнашу, истә калдыру |

**Рус мәктәбенең 7 нче сыйныфында укучы рус балаларына әдәбияттан тәкъдим ителә торган әсәрләр минимумы**

Программада салынган әдәби әсәрләрнең нигезен «Үрнәк прораммада» күрсәтелгән (төзүчеләре: Ф.Х.Җәүһәрова, К.С.Фәтхуллова) әдәби әсәрләр минимумы (7 әсәр) тәшкил итә. Алар түбәндәгеләр:

1) Г.Тукайның «Милли моңнар» шигыре
2) Г.Ибраһимовның «Алмачуар» (хикәядән өзек) әсәре
3) С.Хәкимнең «Бакчачылар» поэмасы;
4) Һ.Такташның «Алсу» поэмасы;
5) Г.Кутуйның «Сагыну» нәсере;
6) М.Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» (повестьтан өзек) әсәре
7) М.Галиевнең «Нигез» (повестьтан өзек) әсәре.

**Ятлау өчен әсәрләр**

Г.Тукайның «Милли моңнар» шигыреннән өзек.
Г.Кутуйның «Сагыну» нәсереннән өзек.
М.Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» повестеннән өзек.
Һ.Такташның «Алсу» поэмасыннан өзек.
Х.Туфанның «Агыла да болыт агыла» шигыреннән өзек.

**Дәрестән тыш (өстәмә) уку өчен тәкъдим ителгән әсәрләр** (укытучы сайлавы буенча):

Мостай Кәрим. Озын-озак балачак.
Нардуган. (Татар халык йоласы) .
Покрау. (Керәшен татарлары бәйрәме).
Уярня. (Мари халык бәйрәме).
Ким Васин. Җыр шулай туды.
Әмирхан Еники. Җиз кыңгырау.
Юрий Семендер. Ике ветеран.
Гәрәй Рәхим. Буыннар елъязмасы.
Марс Шабаев. Күңелемә, эткәй, кайтып кер...
Нәҗип Думави. Габдулла.
Гөлшат Зәйнашева. Үз илемдә.
Фоат Садриев. Юкка көттеләр.
Айрат Суфиянов. Мәктәптән кайтып килеш.
Гавриил Троепольский. Акбай Караколак.
Зиннур Мансуров. Ятим Су анасы.
Гомәр Бәширов. Җидегән чишмә.
Шәйхи Маннур. Печән җыйганда.
Рашат Низами. Куркытылган поши.

**Сөйләшү тематикасы**

Халыкның борынгыдан килгән йолалары.
Тукайлы тормыш.
Асылташларга тиң хәзинәләр.
Халык авыз иҗатының әдәбиятта чагылышы.
Батырлар бар төштә – татарлар бар...
Ватан барыннан да газиз.
Балачакның онытылмас мизгелләре.
Табигать – уртак йортыбыз.

## 3. Календарь-тематик план

| № | Дәрес темасы | Сәгатьләр саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт |
| 1. | Халык авыз иҗаты. Йола фольклоры | 1 | | |
| 2. | Гаилә йолалары | 1 | | |
| 3. | Ф.Бурнаш. «Яшь йөрәкләр» | 1 | | |
| 4 | Календарь йолалар | 1 | | |
| 5. | Бәетләр | 1 | | |
| 6 | Мөнәҗәтләр | 1 | | |
| 7 | Г.Тукай. «Милли моңнар» | 1 | | |
| 8 | Ф.Әмирхан. «Ай өстендә Зөһрә кыз» | 1 | | |
| 9 | Ф.Әмирхан. «Ай өстендә Зөһрә кыз» хикәясенең сәнгатьчә эшләнеше | 1 | | |
| 10 | Н.Исәнбәт. «Җирән Чичән белән Карачәч Сылу» | 1 | | |
| 11 | Г.Ибраһимов. «Алмачуар» хикәясе | 1 | | |
| 12 | Г.Ибраһимов. «Алмачуар» хикәясенең идея-проблематикасы | 1 | | |
| 13 | Г.Ибраһимов. «Алмачуар» хикәясендә Сабантуй бәйрәменең бирелеше | 1 | | |
| 14 | Б.С.Ү. «Ат токымнары» | 1 | | |
| 15 | Д.Т.У. Ким Васин. «Җыр шулай туды» | 1 | | |
| 16 | Татар халкының милли киемнәре һәм бизәнү әйберләре | 1 | | |
| 17 | Р.Миңнуллин. «Килен төшкәндә» | 1 | | |
| 18 | Композитор Рөстәм Яхин | 1 | | |
| 19 | Х. Мөдәррисова. «Көмеш дага» | 1 | | |
| 20 | Б.С.Ү. «Халык авыз иҗатының әдәбиятта чагылышы» | 1 | | |
| 21 | Ә.Маликов. «Ил язмышы – ир язмышы» | 1 | | |
| 22 | Г. Кутуй. «Сагыну» | 1 | | |
| 23 | С. Хәким. «Бакчачылар» | 1 | | |
| 24 | С.Хәким. «Бу кырларда, бу үзәннәрдә...» | 1 | | |
| 25 | Р.Төхфәтуллин. «Җиләкле аланнар» | 1 | | |
| 26 | Р.Төхфәтуллин. «Җиләкле аланнар» повестеның идея-проблематикасы | 1 | | |
| 27 | Р.Төхфәтуллин. «Җиләкле аланнар» әсәренең сәнгатьчә эшләнеше | 1 | | |
| 28 | Д.Т.У. Г.Рәхим. «Буыннар елъязмасы» | 1 | | |
| 29 | М.Мәһдиев. «Без – кырык беренче ел балалары» повестенда чор сурәтләнеше | 1 | | |
| 30 | М.Мәһдиев. «Без – кырык беренче ел балалары» повестенда яшүсмер образы | 1 | | |
| 31 | Скульптор А.Әбдрәшитов | 1 | | |
| 32 | М.Мирза. «Ике сукмак» | 1 | | |
| 33 | Д.Т.У. Марс Шабаев. «Күңелемә, эткәй, кайтып кер... » | 1 | | |
| 34 | Н.Думави. «Беренче кар» | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 35 | Һ.Такташ. «Алсу» поэмасының идея-проблематикасы | 1 | | |
| 36 | Һ.Такташ. «Алсу» поэмасының сәнгатьчә эшләнеше | 1 | | |
| 37 | Б.С.Ү. Дустыма хат язу | 1 | | |
| 38 | Х.Туфан. «Агыла да болыт агыла... » | 1 | | |
| 39 | Х.Туфан. «Тамчылар ни диләр» | 1 | | |
| 40 | Гурий Тавлин. «Кояш болытка кергәндә» | 1 | | |
| 41 | Г.Тавлин. «Кояш болытка кергәндә» | 1 | | |
| 42 | А.Гыйләҗев. «Өч аршын җир» | 1 | | |
| 43 | А.Гыйләҗев. «Өч аршын җир» повестенда туган җир образы | 1 | | |
| 44 | А.Гыйләҗев. «Өч аршын җир» әсәренең идея-проблематикасы | 1 | | |
| 45 | И.Юзеев. «Ак калфагым төшердем кулдан» | 1 | | |
| 46 | И.Юзеев. «Ак калфагым төшердем кулдан» драмасында күтәрелгән проблемалар | 1 | | |
| 47 | И.Юзеев. «Ак калфагым төшердем кулдан» драмасының сәнгатьчә эшләнеше | 1 | | |
| 48 | Б.С.Ү. Г. Зәйнәшева. «Үз илемдә» | 1 | | |
| 49 | Әлфия Авзалова иҗаты | 1 | | |
| 50 | Ф.Сафин. «Туган җиремә» | 1 | | |
| 51 | М. Галиев. «Нигез» | 1 | | |
| 52 | М.Галиев. «Нигез» повестеның идея-проблематикасы | 1 | | |
| 53 | М.Галиев. «Нигез» әсәрендә туган җир образы | 1 | | |
| 54 | М.Галиев. «Нигез» повестеның сәнгатьчә эшләнеше | 1 | | |
| 55 | Ф.Хөсни. «Сөйләнмәгән хикәя» | 1 | | |
| 56 | Ф.Хөсни. «Сөйләнмәгән хикәя» әсәренең идея-проблематикасы | 1 | | |
| 57 | Р.Хафизова. «Әти кайткан көн» | 1 | | |
| 58 | Р.Хафизова. «Әти кайткан көн» әсәренең идея-проблематикасы | 1 | | |
| 59 | Ф.Яруллин. «Ак төнбоек» | 1 | | |
| 60 | Ф.Яруллин. «Ак төнбоек» әсәренең сәнгатьчә эшләнеше | 1 | | |
| 61 | Д.Т.У.Фоат Садриев. «Юкка көттеләр» | 1 | | |
| 62 | Б.С.Ү. Рафис Корбан иҗаты | 1 | | |
| 63 | Р.Галиуллин. «Биш «икеле» | 1 | | |
| 64 | А.Әхмәтгалиева. «Табыш» | 1 | | |
| 65 | М.Әгъләмов. «Сөйли ак каен» | 1 | | |
| 66 | З.Мансуров. «Балык кычкыруы» | 1 | | |
| 67 | Д.Т.У. Гомәр Бәширов. «Җидегән чишмә» | 1 | | |
| 68 | Х. Ибраһим. «Карач» | 1 | | |
| 69 | Б.С.Ү. Татар халкының моңлы сандугачлары | 1 | | |
| 70 | Еллык кабатлау | 1 | | |

**Белем бирүнең укыту-методик һәм матди-техник яктан тәэмин ителеше**

Белем бирүнең укыту-методик һәм матди-техник яктан тәэмин итү нигезенә түбәндәгеләр керә:

- белем һәм тәрбия бирү өчен барлык шартлар да тудырылган, санитария һәм янгыннан саклану нормаларына туры килгән уку бинасы булу;
- әдәбиятны өйрәнү өчен җитәрлек күләмдә дәреслекләр һәм өстәмә методик ярдәмлекләр белән тәэмин ителгән китапханә;
- электрон китапханә, башка электрон ресурслар, татарча сайтлардан куллану мөмкинлеге булган компьютер классы;
- электрон һәм басма күрсәтмә әсбаплар, дәреслекләр;
- мультимедиа укыту программалары, компьютер программалары;
- укучыларының белемнәрен тикшерү программалары;
- төрле типтагы сүзлекләр, энциклопедияләр;
- белешмә материаллар;
- балалар өчен чыгарылган газета һәм журналлар; - интерактив тикшерү программалары;
- татар сайтлары (http://www.tatarile.org.com,http://www.tatknigafund.ru/, http://miras.belem.ru/,http://gabdullatukay.ru/,http://gzalilova.narod.ru/adabiyat_deftere/7kl.html).

**Әдәбият исемлеге**


1. Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Әхмәдуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1990.
2. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007.
3. Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2009.
4. Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2009.
5. Дастаннар. – Казан: Мәгариф, 2001.
6. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау. – Казан: Мәгариф, 2005.
7. Заһидуллина Д.Ф Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Яңадан эшләнгән һәм тулыландырылган басма. – Казан: Мәгариф, 2004.
8. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов А.М. Татар әдәбияты: Теория. Тарих.– Казан: Мәгариф, 2006.
9. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре. 3 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2010.
10. Исламов Ф.Ф. Әдәби викториналар – әдәбиятка, сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләүдә кыйммәтле чара. – Казан, 2005.
11. Йосыпова Н.М. XX гасыр татар шигъриятендә символлар. – Казан: Мәгариф, 2006.
12. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1983 – 2001.
13. Татар әдәбияты. Теория.Тарих./Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанов, Т.Гыйлаҗев, Н.Йосыпова. – Казан: Мәгариф, 2006.
14. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1977, 1979, 1981.

## Күрсәтмә материаллар

1. Электрон ресурслар: “Бала” китапханәсе, “Татар мультфильмнары”, мультимедиа укыту программалары; электрон китапханә; татар сайтлары (belem.ru, tatarile.org.com); аудио һәм видео әсбаплар:
2. Габдулла Тукай. Интерактив мультимедиа уку-укыту әсбабы.
3. Габдулла Тукай. Энциклопедия. Дисклар коллекциясе.
4. «Габдулла Тукай», «Вамин» Татарстанның мәдәни традицияләрен саклау һәм үстерү фонды, DVD и 1 CD дан торган җыентык, 2009.
5. Классик әдәбиятыбыз үрнәкләре. Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар). CD 4 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.
6. Шигърият бакчасында. Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар) CD 1, CD 2, CD 3 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.
7. Гаяз Исхакый. Тормышы һәм иҗатына багышланган методик әсбап. Мультимедиа басма.
8. Язучыларыбыз чыгышлары һәм алар турында истәлекләр. Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар). CD5 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.
9. Язучылар, композиторлар һәм рәссамнар чыгышлары, алар турында истәлекләр. Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия (5-11 сыйныфлар). CD 6 форматлы. Төзүчесе: Газимҗанова Р.Г.

## Мәгълүмат чыганаклары

http://www.mon.gov.ru РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы
http://www.ed.gov.ru Белем бирү буенча федераль агентлык
http://www.fasi.gov.ru Фән һәм инновацияләр буенча федераль агентлык
http://www.obrnadzor.gov.ru Рособрнадзор
http://www.apkppro.ru РФ мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм профессиональ әзерләү академиясе
http://www.lexed.ru Федеральный центр образовательного законодательства
http://www.rustest.ru Федераль тест үткәрү үзәге
http://www. tatedu.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы
http://www.edu. kzn.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Белем полрталы
http://www.mon.tatar.ru
http://pedsovet.org Бөтенроссия интернет-педкиңәшмәсе
http://www.bytik.ru Мәгариф системасында яңа технологияләр куллану – халыкара конференция
http://www.shoolexpo.ru
http://www. it-n.ru
http://. belem.ru
http://. tatar.ru ТР рәсми серверы
http://. tatcenter.ru ТР мәгълүмати – аналитик порталы
http://. Tat. Tatar - inform.ru ТР мәгълүмат агентлыгы
http://. intertat.ru ТР электрон газетасы
http://. vatantat.ru “Ватаным Татарстан” газетасы
http://. Tatar - kongres.ru Бөтендөнья татар конгрессы
http://. xat.ru Татар хат алышу хезмәте
http://. suzlek.ru on- line русча сүзлеге

http://. Abaga.h16.ru “Абага чәчәге” олимпиада
http://. Tugan-tel.at.ru Шрифтлар һәм IT- технологияләр
http://. Kitapxane.at.ru татар телендәге әдәби әсәрләр китапханәсе
http://. Tatar.com.ru татар теле сүзлекләр һәм үзөйрәткечләр
http://. Tatarca.boom.ru татарча текстлар
http://. tataroved.ru Татар тарихы: төрки – татар дөньясы
http://. selet.ru “Сәләт” яшьләр үзәге

**ЭШ ПРОГРАММАЛАРЫН ТӨЗҮ БУЕНЧА МЕТОДИК ТӘКЪДИМНӘР**

РУС ТЕЛЕНДӘ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ 7НЧЕ СЫЙНЫФЫНДА ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАРЫ ӨЧЕН "ТАТАР ТЕЛЕ" ҺӘМ "ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ" ПРЕДМЕТЛАРЫ БУЕНЧА ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Печатается в авторской редакции

Форм. бум. 60х84 1/8. Гарнитура Times.
Усл.печ.л. 5,5

Институт развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
Сайт: irort.ru e-mail: irort2011@gmail.com